Боерык

_22.10.2013_ №_571/24-осн

Казан ш.

**Түбән Кама урманчылыгының урман хуҗалыгы регламентын раслау хакында**

Россия Федерациясе Урман кодексының 87 статьясының 2 өлеше, 2008 елның 22 маенда кабул ителгән “Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында” 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясының 3 өлешендәге 1 пункты нигезендә,
**боерык бирәм:**

1. Түбән Кама урманчылыгының урман хуҗалыгы регламентын расларга.
2. Мәгълүмати технологияләрне үстерү секторы җитәкчесенә (М.В. Киселев) әлеге боерыкны теркәү һәм бастырып чыгаруны техник яктан тәэмин итәргә.
3. Юридик бүлек башлыгына (М.В. Зайцева) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) рәсми төстә бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.
4. Финанс, бухгалтерлык исәбе һәм контрольлеге бүлеге башлыгына (А.К. Ганиева) әлеге боерыкны татар теленә тәрҗемә итүгә бәйле булган чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.
5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Министр в.б. Х.Г. Мусин

Татарстан Республикасы

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы

# Түбән Кама урманчылыгының урман хуҗалыгы регламенты

Казан, 2013 ел

**Эчтәлек**

**КЕРЕШ........................................................................................................5**
Россия Федерациясенең закон чыгару актлары.......................................................6
Урман хуҗалыгы регламентын төзү буенча мәгълүмати база................................13

**1 БҮЛЕК. ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР......................................................... 15**
1.1. Урманчылыкка кыскача сыйфатлама.............................................................15
1.2 Урманнардан файдалануның рөхсәт ителгән төрләре......................................27

**2 БҮЛЕК. УРМАННАРДАН РӨХСӘТЛЕ ФАЙДАЛАНУ НОРМАТИВЛАРЫ, ПАРАМЕТРЛАРЫ ҺӘМ ВАКЫТЛАРЫ, УРМАННАРНЫ САКЛАУ, ЯКЛАУ ҺӘМ ЯҢАДАН ҮСТЕРҮ БУЕНЧА НОРМАТИВЛАР..........................................................................................34**
2.1 Үзагач әзерләгәндә урманнардан рөхсәтле файдалану нормативлары (диләнке хисабы), параметрлары һәм вакытлары..........................................................................................................34
2.2. Урманнардан чәер әзерләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары.........................................................................71
2.3 Урманнардан агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары......................................75
2.4 Урманнардан азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыю өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары..............................89
2.5 Урманнардан аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләре башкару өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары......................................96
2.6. Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары.........................................................................98
2.7. Урманнардан фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеге башкару өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары....................................105
2.8 Урманнардан рекреация эшчәнлеге башкару өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары.......................................................................106
2.9 Урманнардан урман плантацияләре булдыру һәм аларны эксплуатацияләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары............119
2.10 Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре һәм дару үләннәре үстерү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары..........................................................................................................120
2.11 Урманнардан урман үсентеләренең утырту материалларын (чәчкеннәр, үсентеләр) үстерү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары..........................................................................................................121
2.12 Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма байлыкларын чыгару урыннарын эшләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары.......................................................................123
2.13 Урманнардан сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм

эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары.....126
2.14 Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары.....128
2.15 Урманнардан үзагач һәм башка төрле урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары.....136
2.16 Урманнардан дини эшчәнлек өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары.....136
2.17 Урманнарны саклау, яклау һәм яңадан үстерүгә карата таләпләр.....137
2.18 Урманнардан урман үсә торган зоналар һәм урманлы районнар буенча файдалануга карата таләпләрнең үзенчәлекләре.....207

**3 БҮЛЕК. УРМАННАРДАН ФАЙДАЛАНУДА ЧИКЛӘҮЛӘР.....208**
3.1 Урманнардан максатчан файдалану төрләре буенча чикләүләр.....208
3.2 Урман кишәрлекләренең махсус саклана торган төрләре буенча чикләүләр.....210
3.3 Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр.....214

# КЕРЕШ

Әлеге урман хуҗалыгы регламенты – Түбән Кама урманчылыгы урманнарын файдалануны, саклауны, яклауны һәм яңадан җитештерүне гамәлгә ашыру өчен нигез булып тора.

Урман хуҗалыгы регламенты 2006 елның 4 декабрендәге 200-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Урман кодексының (алга таба – РФ УК) 87 статьясының 7 өлеше нигезендә, 2012 елның 4 апрелендәге “Урман хуҗалыгы регламентлары составын, аларны эшләү тәртибен, аларның гамәлдәге вакытын һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында” 126 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган программа буенча эшләнде.

Урман хуҗалыгы регламенты урманчылыкның территориясенә, урман үстерү шартларына карата кулланылучы урманнарны комплексллы үзләштерүнең нормативлары һәм параметрлары җыелмасын үз эченә ала һәм урман кишәрлекләренең хокукый тәртибен билгели.

Урман хуҗалыгы регламенты урманчылык чикләрендә урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан торгызуны гамәлгә ашыручы гражданнар һәм юридик затлар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле (РФ УК 87 ст., 6 ө.).

Урман хуҗалыгы регламентында урманчылык чикләрендә урнашкан урманнарга карата, РФ УК 87 статьясының 5 өлеше нигезендә, түбәндәгеләр аныклана:

– РФ УК 25 статьясы нигезендә билгеләнүче урманнардан файдалануның рөхсәт ителгән төрләре;

– агач кисентеләренең яше, диләнке хисабы, урманнардан файдалану вакытлары һәм алардан рөхсәтле файдалануның башка параметрлары;

– РФ УК 27 статьясы нигезендә урманнардан файдалануны чикләү;

– урманнарны саклау, яклау, яңадан торгызуга карата таләпләр;

Урманнардан файдалануның төрләре буенча ел саен мөмкин булган файдалану күләмнәре урман хуҗалыгы регламентының гамәлдәге вакыты өчен билгеләнгән һәм түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

– урманның кеше сәламәтлеге өчен әйләнә-тирәлекне булдыручы, су саклаучы, яклаучы, санитар-гигиена һәм башка файдалы үзлекләрен саклау һәм көчәйтү;

– җәмгыятьнең урманнарга һәм урман ресурсларына булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү буенча урманнардан күпмаксатлы, рациональ, өзлексез, бетермичә файдалану;

– урманнарның токым составын һәм сыйфатын яңадан үстерү, яхшырту, аларның продуктлылыгын, сакланышын һәм якланылуын арттыру;

– урман фонды җирләреннән рациональ файдалану;

– бердәм техник сәясәт нигезендә урман хуҗалыгын алып баруның нәтиҗәлелеген арттыру, фән, техника һәм алдынгы тәҗрибә казанышларын куллану;

– биологик төрлелеген, тарихи-мәдәни һәм табигый мирас объектларын саклау.

Түбәндәрәк аларга нигезләнеп урман хуҗалыгы регламенты булдырылган норматив-хокукый, норматив-техник, методик закон документларының исемлеге китерелә:

**Россия Федерациясенең Закон чыгару актлары**

2006 елның 4 декабрендәге 200-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Урман кодексы (алга таба – РФ УК).

2006 елның 3 июнендәге 74-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Су кодексы (алга таба – РФ СК).

2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК).

1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Гражданнар кодексы (алга таба – РФ ГК).

1992 елның 21 февралендәге "Җир асты байлыклары турында" 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – "Җир асты байлыклары турында" РФ Законы).

1994 елның 21 декабрендәге "Янгын куркынычсызлыгы турында" 69-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – "Янгын куркынычсызлыгы турында" ФЗ).

1995 елның 14 мартындагы "Махсус саклануч табигый территорияләр турында" 33-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 33-ФЗ номерлы Федераль закон).

1995 елның 24 апрелендәге "Хайваннар дөньясы турында" 52-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 52-ФЗ номерлы Федераль закон).

1995 елның 26 декабрендәге "Геодезия һәм картография турында" 209-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 209-ФЗ номерлы Федераль закон).

1997 елның 19 июлендәге "Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән сак эш итү турында" 109-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 109-ФЗ номерлы Федераль закон).

1997 елның 26 сентябрендәге "Намус иреге һәм дини берләшмәләр турында" 125-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 125-ФЗ номерлы Федераль закон).

2007 елның 24 июлендәге "Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында" 221-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 221-ФЗ номерлы Федераль закон).

1999 елның 31 мартындагы "Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында" 69-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 69-ФЗ номерлы Федераль закон).

2001 елның 18 июнендәге "Җир төзелмәсе турында" 78-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 78-ФЗ номерлы Федераль закон).

2002 елның 10 гыйнварындагы "Әйләнә-тирә мохитне саклау турында" 7-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 7-ФЗ номерлы Федераль закон).

2003 елның 26 мартындагы "Электр энергиясе турында" 35-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 35-ФЗ номерлы Федераль закон).

2003 елның 07 июлендәге "Элемтә турында" 126-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 126-ФЗ номерлы Федераль закон).

2006 елның 04 декабрендәге "Россия Федерациясе Урман кодексын гамәлгә кертү турында" 201-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 201-ФЗ номерлы Федераль закон).

1997 елның 17 декабрендәге "Орлыкчылык турында" 149-ФЗ номерлы Федераль закон (149-ФЗ номерлы Федераль закон).

2009 елның 24 июлендәге "Ау һәм аучылык ресурсларын саклау һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 209-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 209-ФЗ номерлы Федераль закон).

**Аларны җайга салу Россия Федерациясе Урман кодексы һәм аларны җайга салучы норматив-хокукый актлар белән каралган хокукый мөнәсәбәтләр (01.01.2013 елга карата).**

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| **Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары** | | |
| 59 ст. | Сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган урман үсемлекләрен саклау | "Россия Федерациясенең Кызыл китабы турында" 19.02.1996 ел, № 158 РФ Хөкүмәте карары |
| 91 ст. 7 ө. | Дәүләт урман реестрыннан өземтәләр бирүгә түләү күләме һәм аны тотып калу тәртибе | "Дәүләт урман реестрыннан өземтәләр бирүгә түләү күләме һәм аны тотып калу тәртибе турында" 03.03.2007 ел, № 138 РФ Хөкүмәте карары |
| 100 ст. 2 ө.,<br>81 ст. 38 п. | Урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыянның күләмен исәпләп чыгару таксалары һәм методикалары | "Урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыян күләмен исәпләп чыгару турында" 08.05.2007 ел, № 273 РФ Хөкүмәте карары |
| 96 ст. 6 ө.<br>81 ст. 36 п. | Дәүләт урман контролен һәм күзәтчелеген башкару тәртибе | "Федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урман сагын) гамәлгә ашыру турында нигезләмә раслау турында" 22.06.2007 ел, № 394 РФ Хөкүмәте карары |
| 50 ст. 3 ө. | Зат, затлар төркеме тарафыннан әзерләнергә тиешле максималь үзагач күләме | "Зат, затлар төркеме тарафыннан әзерләнергә тиешле максималь үзагач күләмен билгеләү турында" 22.06.2007 ел, № 395 РФ Хөкүмәте карары |
| 73 ст. 4 ө.<br>81 ст. 27 п. | Федераль милектә булган урман кишәрлеге арендасы буенча урман ресурслары күләме бирәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары | "Федераль милектә булган урман кишәрлеге арендасы буенча урман ресурслары күләме берәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары турында" 22.05.2007 ел,<br>№ 310 РФ Хөкүмәте Карары |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 44 ст. | Су объектын файдалануга тапшыру турында карар әзерләү һәм кабул итү тәртибе | "Су объектын файдалануга тапшыру турында карарны әзерләү һәм кабул итү тәртибе турында" 30.12.2006 ел, № 844 РФ Хөкүмәте карары. |
| 45 ст. | Урманнарны линияле объектлар төзүдә файдалану | "Россия Федерациясенең элемтә линияләрен һәм корылмаларын саклау кагыйдәләрен раслау турында" 09.06.1995 ел, № 578 РФ Хөкүмәте карары |
| 76 ст. 3 ө.<br>81 ст. 30 п. | Федераль милектәге җирләрдә әзерләнүче диләнкеләр күләменең берәмлеге өчен түләү ставкалары (урман утыртмаларын сату–алу килешүе өчен) | "Федераль милектә булган урман кишәрлеге арендасы буенча урман ресурслары күләме берәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары турында" 22.05.2007 ел, № 310 РФ Хөкүмәте Карары |
| 55 ст. 3 ө.; 81 ст. 17 п. | Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләре (шул исәптән урман утыртмаларын кисү тәртибе, 16 ст. 3 ө.) | "Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләрен раслау турында" 29.06.2007 ел, № 414 РФ Хөкүмәте Карары |
| 53 ст. 4 ө.; 81 ст. 16 п. | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре (шул исәптән урман утыртмаларын кисү тәртибе, 16 ст. 3 ө.) | "Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында" 30.06.2007 ел, № 417 РФ Хөкүмәте Карары;<br>"Урманнарны янгынга каршы кору турында" 16.04.2011 ел, № 281 РФ Хөкүмәте Карары;<br>"Урманнарда урман янгыннары нәтиҗәсендә барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча көчләрне һәм янгын сагы бүлекчәләре чараларын җәлеп итү кагыйдәләрен раслау турында" 05.05.2011 ел, № 344<br>РФ Хөкүмәте Карары<br>"Урман янгыннары нәтиҗәсендә барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр турында" 17.05.2011 ел, № 376 РФ Хөкүмәте Карары;<br>"Урман янгыннарын сүндерү планын һәм аның формасын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында" 17.05.2011 ел, № 377 РФ Хөкүмәте Карары;<br>"Урманнарда һәм урман янгыннарында янгын куркынычы турындагы мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту кагыйдәләрен раслау турында" 18.08.2011 ел, № 687<br>РФ Хөкүмәте Карары |
| 22 ст. 3 ө. | Урманнарны үзләштерү өлкәсендә өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген әзерләү һәм раслау | "Урманнарны үзләштерү өлкәсендәге өстенлекле инвестиция проектлары турында" 30.06.2007 ел, № 419<br>РФ Хөкүмәте Карары |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | тәртибе | |
| 6 ст. | Урманнар урнашкан җирләрнең категорияләре | "Урман фонды җирләрен башка төр (бүтән) категория җирләренә күчерү турында документлар составы һәм аларны әзерләү тәртибе турында" 28.01.2006 ел, № 48 РФ Хөкүмәте Карары |
| 105 ст. 7 ө. | Урман–парк зоналарының, яшел зоналарның функция зоналарын билгеләү | "Урман-парк зоналарының функция зоналарын, урман-парк зоналарының, яшел зоналарның мәйданын һәм чикләрен билгеләү турында нигезләмә раслау турында" 14.12.2009 ел, №1007 РФ Хөкүмәте Карары |
| 13 ст. | Урман инфраструктурасы | "Саклык урманнары, эксплуатация урманнары һәм резерв урманнары өчен урман инфраструктурасы объектлары исемлеген раслау турында" 2012 елның 17 июнендәге №1283-р РФ Хөкүмәте Әмернамәсе |
| **Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгы актлары (РФ ТРМ)** | | |
| 62 ст. 3 ө.<br>81 ст. 21 п. | Урман торгызу кагыйдәләре | "Урман торгызу кагыйдәләрен раслау турында" 16.07.2007 ел, №183 боерык |
| 64 ст. 3 ө.<br>81 ст. 23 п. | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре (шул исәптән урман утыртмаларын кисү тәртибе, 16 ст. 3 ө.) | "Урманнарны карап тору кагыйдәләрен раслау турында" 16.07.2007 ел, №185 боерык |
| 103 ст. 6 ө.<br>81 ст. 40 п. | Махсус саклануучы табигый территорияләрдә урнашкан урманнарны файдалану, саклау, яклау, яңадан торгызу үзенчәлекләре | "Махсус саклануучы табигый территорияләрдә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү үзенчәлекләрен раслау турында" 16.07.2007 ел, №181 боерык |
| **Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы (Рослесхоз) боерыклары** | | |
| 88 ст. 2 ө. | Урманнарны үзләштерү проектының составы һәм аны эшләү тәртибе | "Урманнарны үзләштерү проектының составын һәм аны эшләү тәртибен раслау турында" 29.02.2012 ел, №69 боерык |
| 104 ст. 2 ө.<br>107 ст. 4 ө. | Су саклау зоналарында урнашкан урманнарны, табигый һәм башка объектларны яклау функциясен үтәүче урманнарны, кыйммәтле урманнарны, һәм шулай ук махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан | "Су саклау зоналарында урнашкан урманнарны, табигый һәм башка объектларны яклау функциясен үтәүче урманнарны, кыйммәтле урманнарны, һәм шулай ук махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү үзенчәлекләрен раслау турында" 14.12.2010 ел, №485 боерык |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | үстерү үзенчәлекләре | |
| 15 ст. 3 ө. | Урман үсү зоналары һәм урманлы районнар | "Россия Федерациясенең урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясенең урманлы районнары исемлеген раслау турында" 09.03.2011 ел, №61 боерык |
| 86 ст. 5 ө. | РФ субъектының урман планы составы һәм планны әзерләү тәртибе | "Россия Федерациясе урман планының типлаштырылган формасын һәм составын, аны әзерләү тәртибен раслау турында" 5.10.2011 ел, №423 боерык |
| 87 ст. 7 ө.<br>81 ст. 34 п. | Урман хуҗалыгы регламентларының составы, аларны эшләү тәртибе, аларның гамәлдәге вакыты һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе | "Урман хуҗалыгы регламентларының составын, аларны эшләү тәртибен, аларның гамәлдәге вакытын һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында" 04.04.2012 ел, №126 боерык |
| 81 ст. | Урманнарны саклык категорияләре буенча аеру | "Урманнарны кыйммәтле урманнарга, эксплуатацияләнүче урманнарга, резервтагы урманнарга кертү буенча вакытлы күрсәтмәләрне раслау турында" 26.08.2008 ел, №237 боерык |
| 15 ст. 4 ө. | Кисентеләрнең яше | "Кисентеләрнең яшен билгеләү турында" 19.02.2008 ел, №37 боерык |
| 29 ст. 5 ө.<br>81 ст. 1 п. | Диләнке хисабын исәпләп чыгару тәртибе | "Диләнке хисабын исәпләп чыгару тәртибе турында" 27.05.2011 ел, №191 боерык |
| 29 ст. 9 ө.<br>81 ст. 4 п. | Үзагач әзерләү кагыйдәләре (шул исәптән урман утыртмаларын кисү тәртибе, 16 ст. 3 ө.) | "Үзагач әзерләү кагыйдәләрен раслау турында" 01.08.2011 ел, №337 боерык |
| 39.1 ст. | Урман үсемлекләренең утырту материалларын үстерү | "Урманнардан урман үсемлекләренең утырту материалларын (үсентеләрне, чәчкеннәрне) үстерү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 19.07.2011 ел, №308 боерык |
| 45 ст. | Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану | "Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 10.06.2011 ел, №223 боерык |
| 43 ст. | Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне башкару һәм файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару өчен файдалану | "Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне башкару һәм файдалы казылма ятмаларын эшләү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 27.12.2010 ел, №515 боерык |
| 31 ст. | Чәер әзерләү | "Чәер әзерләү кагыйдәләрен раслау турында" 24.01.2012 ел, №23 боерык |
| 91 ст. 9 ө.; 81 ст. 35 п. | Дәүләти урман реестрын алып бару тәртибе | "Дәүләти урман реестрын алып бару турында" 30.05.2011 ел, № 194 боерык;<br>"Дәүләти урман реестрын алып бару рәвешләрен раслау турында" 15.02.2012 ел, |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | №194 боерык |
| 32 ст. | Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу | "Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу турында" 05.12.2011 ел, №512 боерык |
| 39 ст. | Җимешле, җиләкле декоратив урман үсемлекләрен үстерү | "Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 05.12.2011 ел, № 510 боерык |
| 34 ст. | Азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үсемлекләрен әзерләү | "Азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үләннәрен әзерләү кагыйдәләрен раслау турында" 05.12.2011 ел, №511 боерык |
| 40 ст. | Фәнни-тикшерену эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча урманнардан файдалану | "Урманнардан фәнни-тикшерену эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 23.12.2011 ел, №548 боерык |
| 41 ст. | Рекреация эшчәнлеген башкару өчен урманнардан файдалану | "Урманнардан рекреация эшчәнлеген башкару өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 21.02.2012 ел, №62 боерык |
| 104 ст.<br>105 ст. | Су саклау зоналарында урнашкан урманнардан, табигый һәм башка объектларны яклау функциясен үтәүче урманнардан, кыйммәтле урманнардан, һәм шулай ук махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнардан файдалану | "Су саклау зоналарында урнашкан урманнардан, табигый һәм башка объектларны яклау функциясен үтәүче урманнардан, кыйммәтле урманнардан, һәм шулай ук махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү үзенчәлекләрен раслау турында" 14.12.2010 ел, №485 боерык |
| 49 ст. 3 ө.<br>81 ст. 14 п. | Урманнардан файдалану буенча хисап рәвеше һәм аны тапшыру тәртибе | "Урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү, урман үрчетү турында хисапларның рәвешләрен һәм аларны тапшыру тәртибен билгеләү турында" 14.02.2012 ел, №47 боерык |
| 60 ст. 2 ө.<br>81 ст. 20 п. | Урманнарны саклау һәм алардан файдалану буенча хисап рәвеше һәм аны тапшыру тәртибе | "Урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү, урман үрчетү турында хисапларның рәвешләрен һәм аларны тапшыру тәртибен билгеләү турында" 14.02.2012 ел, №47 боерык |
| 63 ст. 2 ө.<br>81 ст. 22 п. | Урман үрчетү кагыйдәләре | "Урман үрчетү кагыйдәләрен раслау турында" 10.01.2012 ел, №1 боерык |
| 66 ст. 2 ө.<br>81 ст. 25 п. | Урманнарны яңадан үстерү һәм урман үрчетү турында хисап рәвеше, аны тапшыру тәртибе | "Урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү, урман үрчетү турында хисапларның рәвешләрен һәм аларны тапшыру тәртибен билгеләү турында" 14.02.2012 ел, №47 боерык |
| 89 ст. 1 ө. | Урманнарны үзләштерү | "Урманнарны үзләштерү проектының дәүләт |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | проектының дәүләт һәм муниципаль экспертизасы тәртибе | һәм муниципаль экспертизасы тәртибен раслау турында" 22.12.2011 ел, №545 боерык |
| 26 ст. 3 ө.<br>81 ст. 3 п. | Урман декларациясенең рәвеше, аны тутыру һәм тапшыру тәртибе | "Урман декларациясе турында" 17.01.2012 ел, №18 боерык |
| 77 ст. 5 ө.<br>81 ст. 31 п. | Дәүләт яки муниципаль милектәге урман утыртмаларын сату-алу килешүләрен әзерләү һәм төзү тәртибе, һәм урман утыртмаларын сату-алу килешүенең үрнәк рәвеше | "Дәүләти һәм муниципаль милектәге җирләрдә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу килешүләрен әзерләү һәм төзү тәртибен, һәм Урман утыртмаларын сату-алу килешүенең үрнәк рәвешен раслау турында" 26.07.2011 ел, № 318 боерык |
| 74 ст. 5 ө.<br>29 һәм 28 п.<br>81 ст. | Дәүләти яки муниципаль милектәге урман кишәрлеге арендасы килешүен әзерләү һәм төзү тәртибе, һәм урман кишәрлеге арендасы килешүенең үрнәк рәвеше | "Дәүләти яки муниципаль милектәге урман кишәрлеге арендасы килешүен әзерләү һәм төзү тәртибен, һәм урман кишәрлеге арендасы килешүенең үрнәк рәвешен раслау турында" 26.07.2011 ел, № 319 боерык |
| 38 ст. | Урманнардан авыл хуҗалыгын алып бару өчен файдалану | "Урманнардан авыл хуҗалыгын алып бару өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 05.12.2011 ел, №509 боерык |
| 26 ст. 6 ө.<br>81 ст. 2 п. | Үзагачын әзерләү рөхсәт ителмәгән агачларның һәм куакларның төрләре (токымнары) исемлеге | "Үзагачын әзерләү рөхсәт ителмәгән агачларның һәм куакларның төрләре (токымнары) исемлеген раслау турында" 05.12.2011 ел, №513 боерык |
| 46 ст. 3 ө.<br>81 ст. 13 п. | Урманнардан үзагач һәм башка урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләре | "Урманнардан үзагач һәм башка урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында" 12.12.2011 ел, № 517 боерык |
| 53 ст. 4 ө.; 81 ст. 16 п. | Урманнарда янгын һәм санитар иминлек кагыйдәләре | "Урманнарда янгын куркынычсызлыгын яисә санитар иминлекне тәэмин итү максатларында гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чараларының үтеп керүен, урманнарда билгеле бер эш төрләрен үткәрүне чикләү тәртибен раслау турында" 03.11.2011 ел, №471 боерык<br>"Урманнарны янгынга каршы кору турында турында" 27.04.2012 ел,<br>№174 боерык<br>"Урманнарның табигый янгын куркынычы классификациясен һәм, урманнардагы һава торышына карап, табигый янгын куркынычы классификациясен раслау турында" 05.07.2011 ел, № 287 боерык |
| 67 ст.<br>68 ст. | Урман коруны үткәрү кагыйдәләре | "Урман кору күрсәтмәсен раслау турында" 12.12.2011 ел, №516 боерык. |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексы белән каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | Санитар-тернәкләндерү чараларын үткәрү буенча күрсәтмә, Зарарлы организмнар чыккан урыннарны юк итү һәм бетерү буенча күрсәтмә, Урманнарны патологик яктан мониторинглауны проектлау, оештыру һәм алып бару буенча күрсәтмә һәм Урманнарны патологик тикшеренүләрне планлаштыру, оештыру һәм алып бару буенча күрсәтмә | "Методик документларны раслау турында" 29.12.2007 ел, №523 боерык. |
| **Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары** | | |
| 82, 83 ст. | | 2008 елның 22 маендагы "Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында" 22-ТРЗ номерлы ТР Законы; 2009 елның 16 мартындагы "Татарстан Республикасының Урман планын раслау турында" ПУ-146 номерлы ТР Президенты Указы "2011-2020 елларда Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгын үстерү" Дәүләт программасын раслау турында" 30.07.2013 ел, № 531 ТР МК Карары |

## Урман хуҗалыгы регламентын төзү буенча мәгълүмати база

Урман хуҗалыгы регламентын эшләгәндә түбәндәгеләрдән файдаланылды:

– законнар, методик һәм норматив документлар нигезендә яшь класслары ысулы белән башкарылган 2012 елның урманкору материаллары;

– җир корылышы материаллары;

– Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы идарәсе органнарының исемлек һәм статистика хисаплылыгы;

– РФ Юстиция министрлыгында теркәлгән норматив-хокукый актлар.

Аларны Урман кодексына ярашлы торышка китерү өчен түбәндәге гамәлләр башкарылды:

– 01.01.2013 елга карата дәүләти урман реестры күрсәткечләре нигезендә урманчылыкның мәйданы билгеләнде.

– урманчылык кишәрлекләре буенча урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре билгеләнде;

– әзерләнгәннең күләме (диләнке хисабы), өлгергән һәм картайган утыртмаларны сайланма һәм тоташ кисүләрдә урманнарны рөхсәтле файдалануның параметрлары һәм вакытлары хисапланды;

– урманнарны карап тотканда, санитар-сәламәтләндерү чараларын үткәргәндә урта яшьле, өлгереп килүче утыртмаларны кискәндә әзерләнүче үзагач күләмнәре хисапланды;

– урманнардан чәер әзерләү буенча рөхсәтле файдалануның нормативлары, параметрлары һәм вакытлары билгеләнде,

– агач булмаган урман ресурсларын әзерләү буенча урманнардан рөхсәтле файдалануның нормативлары, параметрлары һәм вакытлары билгеләнде;

– азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу буенча урманнардан рөхсәтле файдалануның нормативлары, параметрлары һәм вакытлары билгеләнде.

Әлеге урман хуҗалыгы регламенты 19.03.2009 ел, №151 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары белән расланды.

Урман хуҗалыгы регламенты 10 елга (2019 елның мартына кадәр) кадәрге вакытка эшләнде.

Регламентны эшләүче булып түбәндәгеләр санала:

ФГУП "Рослесинфорг" "Поволжский леспроект" Казан экспедиция филиалы, 420087, Казан ш., Г. Кутуй ур. – 155 а (2008 елның 18 февралендәге 64 номерлы дәүләт контракты).

Үзгәрешләр кертүче оешмалар турында белешмәләр:

2010 елда – ФГУП "Рослесинфорг" Казан филиалы, 420087, Казан ш., Г. Кутуй ур. – 155 а (2010 елның 29 октябрендәге 441 номерлы дәүләт контракты).

2013 елда – "Ульяновсклеспроект" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять, Ульян ш., Орлов ур., 21 а, тел. (8422) 72-79-29 (2012 елның 25 декабрендәге 815 номерлы дәүләт контракты).

# 1 БҮЛЕК. ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР

## 1.1. Урманчылыкка кыскача сыйфатлама

### 1.1.1. Урманчылыкның исеме һәм урнашкан урыны

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Түбән Кама урманчылыгы (алга таба – Урманчылык) Татарстан Республикасының төньяк-көнбатыш өлешендә Түбән Кама, Зәй, Сарман, Тукай муниципаль районнары территорияләрендә урнашкан.

Урманчылыкның конторасы Түбән Кама шәһәренең Татарстан Республикасы башкаласы Казаннан 280 чм ераклыктагы Красный Ключ поселогында урнашкан.

Урманчылык территориясенең төньяктан көньякка кадәр озынлыгы – 55 чм, көнчыгыштан көнбатышка кадәр – 50 чм.

Урманчылыкның почта адресы: 423552, Татарстан Республикасы, Түбән Кама ш., Красный Ключ п., Совет ур., 28 йорт.

### 1.1.2. Урманчылыкның һәм кишәрлек урманчылыкларының гомуми мәйданы

01.01.2013 елга карата Урманчылыкның гомуми мәйданы – 43486 га, шул исәптән кишәрлек урманчылыклары буенча:

Биклән кишәрлеге урманчылыгы – 8486 га;

Кызыл Юл кишәрлеге урманчылыгы – 9069 га;

Баграж кишәрлеге урманчылыгы – 8955 га;

Ворошлиов кишәрлеге урманчылыгы – 6587 га;

Ләке кишәрлеге урманчылыгы – 10389 га;

### 1.1.3. Урманчылык территориясен муниципаль берәмлекләр буенча бүлгәләү

Урманчылык территориясен муниципаль берәмлекләр буенча бүлгәләү 1.1.3 таблицада китерелә.

1.1.3 таблица

**Урманчылыкның структурасы**

| № п/п | Урман кишәрлекләренең исеме | Административ район (муниципаль берәмлек) | Гомуми мәйданы, га |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Биклән | Түбән Кама | 8267 |
| | | Тукай | 219 |
| | Кишәрлек урманчылыгы буенча җәмгысе: | | 8486 |
| 2. | Кызыл Юл | Түбән Кама | 5372 |
| | | Тукай | 53 |
| | | Зәй | 3644 |
| | Кишәрлек урманчылыгы буенча җәмгысе: | | 9069 |
| 3. | Баграж | Зәй | 8955 |

| № п/п | Урман кишәрлекләренең исеме | Административ район (муниципаль берәмлек) | Гомуми мәйданы, га |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 4. | Ворошилов | Тукай | 354 |
| | | Зәй | 6233 |
| | Кишәрлек урманчылыгы буенча җәмгысе: | | 6587 |
| 5. | Ләке | Зәй | 9063 |
| | | Сарман | 1326 |
| | Кишәрлек урманчылыгы буенча җәмгысе: | | 10389 |
| | Урманчылык буенча барлыгы | | 43486 |
| | административ районнар буенча: | Түбән Кама | 13639 |
| | | Тукай | 626 |
| | | Зәй | 27895 |
| | | Сарман | 1326 |

Урманчылык төньяктан Чулман елгасына тоташа, төньяк-көнчыгыштан Алабуга урманчылыгы, көньяк-көнчыгыштан – Азнакай урманчылыгы, көньяктан - Әлмәт урманчылыгы, көньяк-көнбатыштан – Зәй шәһәрендәге җирләр, көнбатыштан - Зәй урманчылыгы белән чиктәш тора.

Урманчылыкның урман фонды 10 эреләндерелгән массив рәвешендә, алар Урманчылык территориясендә тигез итеп урнашкан һәм алар арасында төрлек зурлыктагы зур булмаган урман утраучыклары урнашкан.

Урман фонды урнашкан муниципаль район территориясенең урманлылыгы 26%, бу Татарстан Республикасы буенча уртача урманнар капламыннан (17%) сизелерлек югары.

### 1.1.4. Татарстан Республикасының Урманчылык территориясе аерып күрсәтелгән схематик картасы

Татарстан Республикасының Урманчылык территориясе аерып күрсәтелгән схематик картасы № 1 карта-схемада күрсәтелгән.

### 1.1.5. Урманчылык урманнарын урман үсү зоналарына һәм урманлы районнарга бүлү

"Россия Федерациясенең урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясенең урманлы районнары исемлеген раслау турында" 09.03.2011 ел, №61 Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы боерыгы белән расланган урман үсү районнарына бүлү нигезендә, урманчылык территориясе Россия Федерациясенең Европа өлешендәге урман-дала зонасының урман-дала районына кертелгән (1.1.5 таблица).

1.1.5 таблица

**Урманчылык урманнарын урман үсү зоналарына һәм урманлы районнарга бүлү**

| № п/п | Урман кишәрлекләренең исеме | Урман үсү зонасы | Урманлы район | Урман кварталлары исемлеге | Мәйданы, га |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Биклән | Урман-дала зонасы | Россия Федерациясенең Европа өлешендәге Урман-дала районы | 1-40; 42-48; 50-59; 64-119 | 8486 |
| 2. | Кызыл Юл | Урман-дала зонасы | Россия Федерациясенең Европа өлешендәге Урман-дала районы | 1-83 | 9069 |
| 3. | Баграж | Урман-дала зонасы | Россия Федерациясенең Европа өлешендәге Урман-дала районы | 1-2; 4-53; 55-63; 70-100 | 8955 |
| 4. | Ворошилов | Урман-дала зонасы | Россия Федерациясенең Европа өлешендәге Урман-дала районы | 1-70 | 6587 |
| 5. | Ләке | Урман-дала зонасы | Россия Федерациясенең Европа өлешендәге Урман-дала районы | 1-50, 52, 54-82, 86, 89-133 | 10389 |
| | Барлыгы: | | | | 43486 |

Урманчылык территориясенең Урманчылык территориясен һәм урман үсү зоналары һәм урманлы районнар буенча кишәрлек урманчылыкларын аерып күрсәткән схематик картасы № 2 карта-схемада күрсәтелгән.

Карта-схема N1. Схематическая карта Республики Татарстан с выделением территории лесничества.




- Нижнекамское лесничество

Карта-схема N2. Распределение территории лесничества по лесорастительным зонам и лесным районам.



## 1.1.6. Урманнарны максатчан билгеләнеше һәм саклык урман категорияләре буенча бүлү

Урманнарны максатчан билгеләнеше һәм кварталлар яки аларның өлешләре буенча саклык урманнарына бүлү, һәм шулай ук саклык һәм эксплуатация урманнарын бүлеп чыгаруга нигезләр 1.1.6.1 таблицада китерелгән.

1.1.6.1 таблица.

**Урманнарны максатчан билгеләнеше һәм саклык урманнары категорияләре буенча бүлү**

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яисә аларның өлешләренең номерлары | Мәйданы, га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлүнең нигезләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Барлыгы урманнар | | | 43486 | РФ Урман кодексы, РФ Су кодексы, 04.12.2006 ел, №201-ФЗ Федераль закон, 26.08.2008 ел, №237 "Урманнарны кыйммәтле урманнарга, эксплуатация урманнарына, резерв урманнарына кертү буенча вакытлыча күрсәтмәләрне раслау турында" Рослесхоз боерыгы, 12.12.2011 ел, №516 Рослесхоз боерыгы белән расланган Урман корылышы инструкциясе. |
| Саклык урманнары, барлыгы | | | 12675 | |
| Су саклау зоналарында урнашкан урманнар | Биклән | 44, 53, 65, 78, 79, 80, 83, 86, 87, 89, 90, 94, 98, 103, 105,107-109 кв. өл | 139 | |
| | Кызыл Юл | 1, 2, 4, 6, 7, 14, 16, 19-23, 25, 29-33, 41, 42, 44, 45, 46, 52-55,58-63 кв. өл. | 293 | |
| | Баграж | 11, 16, 17, 20, 25, 31, 37-41, 43-46, 48, 49, 51, 52, 53, 80, 83, 85 кв. өл. | 223 | |
| | Ворошилов | 3, 4, 5, 27, 28, 29, 33, 34, 43, 45, 47, 50, 54, 55, 59, 60 квартал өлешләре | 194 | |
| | Ләке | 4, 5, 12, 15, 16, 23, 55, 56, 60-62, 64-67, 103-107, 109-112, 114, 116, 132 квартал өлешләре | 183 | |
| | Барлыгы: | | 1032 | |
| Табигый һәм башка төр объектларны саклау функциясен үтәүче урманнар, барлыгы | | | 6722 | 04.12.2006 ел, №201-ФЗ Федераль закон, 14.07.1944 ел, №1457-р СССР ХКС әмернамәсе, 18.07.1959 ел, №4292 РСФСР МС әмернамәсе һәм 31.12.2003 ел, №702 ТР МК Карары белән расланган Гомуми файдаланудагы |
| Россия Федерациясе субъектлары милкендә булган, гомуми кулланылыштагы тимер юл, гомуми кулланылыштагы федераль автомобиль юллары, гомуми | Биклән | 40, 42, 43, 45-48, 50, 51, 52, 54-56, 58, 59, 64, 69-77, 85, 87 кв., 44, 53, 65, 86, 97, 106, 107, 110 кв. өл. | 1586 | |
| | Баграж | 18, 19, 27, 28, 36, 37, 44 кв. өл. | 187 | |
| | Ворошилов | 26, 34 квартал | 69 | |

<table>
<tr><th>Урманнарның максатчан билгеләнеше</th><th>Кишәрлек урманчылыгы</th><th>Кварталларның яисә аларның өлешләренең номерлары</th><th>Мәйданы, га</th><th>Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлүнең нигезләре</th></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td><td>5</td></tr>
<tr><td rowspan="3">кулланылыштагы автомобиль юллары буйларындагы саклык урманнары полосалары</td><td></td><td>өлешләре</td><td></td><td rowspan="3">автомобиль юллары исемлеге нигезендә</td></tr>
<tr><td>Ләке</td><td>30 кв., 23, 33, 37, 42, 43, 44, 65, 66 квартал өлешләре</td><td>405</td></tr>
<tr><td colspan="2">Барлыгы:</td><td>2247</td></tr>
<tr><td rowspan="2">яшел зоналар</td><td>Баграж</td><td>70-79, 96, 97, 98 кварталлар</td><td>1055</td><td rowspan="2">04.12.2006 ел, №201-ФЗ Федераль закон, 01.07.1963 ел,№2724-р РСФСР МС әмернамәсе, 02.03.1963 ел, № 8, 14.10.1963 ел, №35р ТАССР МС карары</td></tr>
<tr><td colspan="2">Барлыгы:</td><td>1055</td></tr>
<tr><td rowspan="2">урман-парк зоналары</td><td>Биклән</td><td>1-39, 57 кварталлар</td><td>3420</td><td rowspan="2">04.12.2006 ел, № 201-ФЗ Федераль закон, 26.08.1968 ел, №30 ТАССР МС карары</td></tr>
<tr><td colspan="2">Барлыгы:</td><td>3420</td></tr>
<tr><td colspan="3">Кыйммәтле урманнар, барлыгы:</td><td>4921</td><td rowspan="7">04.12.2006 ел, №201-ФЗ Федераль закон, 31.08.1983 ел, №1981-р РСФСР МС әмернамәсе, 16.06.2010 ел, №232 "Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында" Рослесхоз боерыгы</td></tr>
<tr><td rowspan="6">кеше аз йөри торган ярымдала, урман-дала, урман-тундра зоналарында, далаларда, тауларда урнашкан урманнар</td><td>Биклән</td><td>111-119 кварталлар</td><td>733</td></tr>
<tr><td>Кызыл Юл</td><td>69-79 кварталлар</td><td>1076</td></tr>
<tr><td>Баграж</td><td>1, 2, 55-63, 89-95, 99-100 кварталлар</td><td>1370</td></tr>
<tr><td>Ворошилов</td><td>61-70 кварталлар</td><td>317</td></tr>
<tr><td>Ләке</td><td>52, 54, 68-82, 86, 133 кварталлар,</td><td>781</td></tr>
<tr><td colspan="2">Барлыгы:</td><td>4277</td></tr>
<tr><td rowspan="2">су объектлары буенда урнашкан тыюлы урман полосалары</td><td>Баграж</td><td>82, 84, 86 кв; 83, 85 кв. өлешләре</td><td>644</td><td rowspan="2">04.12.2006 ел, №201 - ФЗ Федераль закон, 01.07.1963 ел, № 1981-р РСФСР МС әмернамәсе, 16.06.2010 ел, №232 "Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында" Рослесхоз боерыгы</td></tr>
<tr><td colspan="2">Барлыгы</td><td>644</td></tr>
</table>

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яисә аларның өлешләренең номерлары | Мәйданы, га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлүнең нигезләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Эксплуатация урманнары | Биклән | 66-68, 81, 82, 84, 88, 91, 92, 93, 95, 96, 99, 100-102, 104 кв., 78-80, 83, 85-87, 89, 90, 94, 97, 98, 103, 105-110 кв. өлешләре | 2608 | 04.12.2006 ел, № 201-ФЗ Федераль закон, 23.04.1943 ел, №430 СССР ХКС әмернамәсе, 16.06.2010 ел, №232 "Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында" Рослесхоз боерыгы |
| | Кызыл Юл | 3, 5, 8-13, 15, 17, 18, 24, 26-28, 35-40, 43, 47-51, 56, 57, 64-68 кв. 1, 2, 4, 6, 7, 14, 16, 19-23, 25, 29-34, 41-42, 44-46, 52-55, 58-63 кв. өл. | 7700 | |
| | Баграж | 1, 2, 4-10, 12-15, 21-24, 26, 29, 30, 32-35, 42, 47, 50, 87-88 кв., 11, 16-20, 25, 27, 28, 31, 36-41, 43-46, 48-49, 51-53 кв. өл. | 5476 | |
| | Ворошилов | 1, 2, 6-25, 30-32, 35, 36, 37, 38, 39, 40, 41, 42, 44, 46, 48-53, 56-58 кв., 3-5, 26-29, 33-34, 43, 45, 47, 50, 54, 55, 59-60 кв. өл. | 6007 | |
| | Ләке | 1-3, 6-11, 13, 14, 17-22, 24-29, 31, 32, 34-36, 38-41,45-50, 57, 58, 59, 63, 89-102, 108, 113, 115, 117-131 кв., 4, 5, 12, 15, 16, 23, 33, 37, 42-44, 55, 56, 60-62, 64-67, 103-107, 109-112, 114, 116, 132 кв. өлешләре | 9020 | |
| | Барлыгы: | | 30811 | |

Урманнарны максатчан билгеләнеше һәм саклык урман категорияләре буенча бүлү 1.1.6.2 таблицада күрсәтелгән.

1.1.6.2 таблица

**Урманнарны максатчан билгеләнеше һәм саклык урманнары категорияләре буенча бүлү**

Мәйданы, га

| Кишәрлек урманчылыгы | Барлыгы урман нар | Саклык урман нары, барлыгы | Шул исәптән саклык урманнары категорияләре | | | | | | | | | | | | Эксплуатация урман нары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | МСТТ урнашкан урман нар | Су саклау зоналарында урнашкан урман нар | Табигый һәм башка төр объектларны саклау функциясен үтәүче урманнар, барлыгы | шул исәптән: | | | Кыйммәтле урман нар, барлыгы | шул исәптән: | | | | | |
| | | | | | | гомуми файдаланудагы т/юл, гомуми файдаланудагы федераль а/ю, гомуми файдаланудагы РФ субъектлары милкендә булган а/ю буйларында урнашкан саклык урман полосалары. | Яшел зоналар | Урман-парк зоналары | | Су объектлары буенда урнашкан тыюлы урман полосалары | Уылдык саклаучы урман полосалары | Эрозиягә каршы көрәш урманнары | Кеше аз йөри торган ярымдала, урман-дала, урман-тундра зоналарында, далаларда, тауларда урнашкан урманнар | Фәнни яисә тарихи әһәмияткә ия урманнар | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
| Биклән | 8410 | 5802 | | 139 | 5006 | 1586 | | 3420 | 733 | | | | 733 | | 2608 |
| Кызыл Юл | 9027 | 1327 | | 293 | - | | | | 1076 | | | | 1076 | | 7700 |
| Баграж | 8873 | 3397 | | 223 | 1242 | 187 | 1055 | | 2014 | 644 | | | 1370 | | 5476 |
| Ворошилов | 6452 | 445 | | 194 | 69 | 69 | | | 317 | | | | 317 | | 6007 |
| Ләке | 10364 | 1344 | | 183 | 405 | 405 | | | 781 | | | | 781 | | 9020 |
| Барлыгы* | 43126 | 12315 | | 1032 | 6722 | 2247 | 1055 | 3420 | 4561 | 644 | | | 3917 | | 30811 |
| Барлыгы** | 43486 | 12675 | | 1032 | 6722 | 2247 | 1055 | 3420 | 4921 | 644 | | | 4277 | | 30811 |

* "Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле урманнарга, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында" 16.06.2010 ел, № 232 Рослесхоз боерыгы нигезендә

** 01.01.2013 карата урман фонды исәбе күрсәткечләре нигезендә (чираттагы тапкыр урманкоруны үткәргәндә күрсәткечләр аныклауны таләп итә)

## 1.1.7. Урманчылык территориясенең урман фонды җирләре составындагы урман һәм урман булмаган җирләрнең сыйфатламасы

1.1.7 таблица

**Урманчылык территориясенең урман фонды җирләре составындагы урман һәм урман булмаган җирләрнең сыйфатламасы**

| Җирләрнең категорияләре | Урманчылык буенча барлыгы | |
|---|---|---|
| | Мәйданы, га | % |
| 1 | 2 | 3 |
| Җирләрнең гомуми мәйданы | 43486 | 100 |
| Урманлы җирләр - барлыгы | 41688 | 95,9 |
| Урман үсемлекләре белән капланган җирләр - барлыгы | 41014 | 94,3 |
| шул исәптән: урман культуралары | 11805 | 27,1 |
| Урман үсемлекләре белән капланмаган урманнар - барлыгы | 674 | 1,6 |
| шул исәптән: | | |
| - тоташмаган урман культуралары | 488 | 1,1 |
| - урман питомниклары; плантацияләр | 21 | - |
| - табигый аралыклар | - | |
| - урман торгызу фонды, барлыгы | 165 | 0,4 |
| шул исәптән: | | |
| - көекләр | - | |
| - кисү | 115 | 0,3 |
| - аланлыклар, ташландык урыннар | 50 | 0,1 |
| Урмансыз җирләр - барлыгы | 1798 | 4,1 |
| шул исәптән: | | |
| - сөрүлекләр | 2 | - |
| - печән чабу урыннары | 39 | 0,1 |
| - утлавыклар | 119 | 0,3 |
| - сулар | 47 | 0,1 |
| - бакчалар, җиләклекләр | 3 | - |
| - юллар, агач кисеп салынган юллар | 395 | 0,9 |
| - утарлар һ.б. | 130 | 0,3 |
| - сазлар | 159 | 0,4 |
| - пасекалар | 8 | - |
| - башка җирләр | 896 | 2,1 |

## 1.1.8. Булган махсус саклануча табигый территорияләрнең һәм объектларның, аларны оештыру, экологик челтәрләрен үстерү, биотөрлелегең саклау буенча планнарының сыйфатламасы

Алга таба санап үтелгән территорияләрнең (кишәрлекләрнең) хокукый режимы РФ УК 103 ст. белән билгеләнә. Әлеге җирләр әйләнештән чыгарылган яки әйләнештә чикләнгән (РФ ҖК 27 ст.).

Махсус саклануча табигый территорияләрдә, шул исәптән урманнарны файдалану, саклау, яклау һәм яңадан үстерү өлкәсендә тыелган яисә рөхсәт ителгән эшчәнлекнең конкрет төрләре РФ ҖК, РФ УК, "Махсус саклануча табигый территорияләр турында" 14.03.1995 ел, №33-ФЗ Федераль закон, һәм

шулай ук аларны үтәү өчен чыгарылган Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары белән билгеләнә.

Аларда хуҗалыкны алып бару режимы түбәндәгеләрне тыя:

табигый процессларга кешенең теләсә нинди йогынтысы тыелган кишәрлекләрдәге урман утыртмаларын кисү;

әгәр бу махсус сакланучы табигый территорияләрнең чикләрендә каралган функция зоналарының хокукый режимы белән башкасы каралмаган булса, урман утыртмаларын тоташ кисү;

җирләрне теләсә нинди файдалануга бүлү;

теләсә нинди коммуникацияләрне салу;

территорияне төзеп тутыру, чүпләү яисә иске-москы белән тутыру;

терлек куу, йөртү, печән чабу;

файдалы казылмалар табу;

биосфера полигоннарыннан гайре, урманнарны саклау һәм яклау өчен, шул исәптән фәнни максатларда агулы химия препаратларын куллану;

автотранспортны кертү һәм туктатып тору;

туристлык тукталышларын кору, учаклар ягу;

агач булмаган урман ресурсларының түбәндәге үсемлек төрләрен әзерләү һәм җыеп алу: РФ Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгәннәрне;

җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үсемлекләрен үстерү;

кирәкмәгән агачларны кисү һәм башка төр кисүләр әлеге территорияләр өчен билгеләнгән режимда башкарыла.

Дини, урман торгызу эшчәнлеген башкару рөхсәт ителә.

Ау, авыл хуҗалыгын алып бару, фәнни-тикшеренү, мәгариф, рекреация эшчәнлеген башкару, урман плантацияләрен булдыру, җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару, ятмаларны эшләп чыгару, сусаклагыч һәм башка төр су объектларын төзү һәм эксплуатацияләү әлеге территорияләр өчен билгеләнгән режим нигезендә чикләнә.

Урманчылык территориясендә махсус сакланучы табигый территорияләр юк.

### 1.1.9. Булган урман, урман эшкәртү инфраструктурасы объектларының, урман инфраструктурасын булдыруга бәйле булмаган объектларның, әлеге объектларны төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү буенча чараларның территориаль планлаштыру документларында каралган сыйфатламасы

1.1.9.1 Урман инфраструктурасы объектлары

Урман инфраструктурасы объектларына урман юллары, урман саклыкханәләре һәм урманнарны саклау, яклау һәм яңадан үстерү өчен кулланылучы башка объектлар, асылда квартал урман юллары, чик линияләре, квартал һәм күрсәтмә баганалар, урман хуҗалыгы билгеләре керә.

Саклык урманнары, эксплуатация урманнары һәм резерв урманнары өчен урман инфраструктурасы объектлары исемлеге 17.07.2012 ел, №1283-р РФ Хөкүмәте әмернамәсе белән расланган.

Россия Федерациясе Урман кодексының 13 статьясы нигезендә урман юллары урманнардан теләсә нинди файдалану төрләрендә булдырылырга мөмкин.

Бар булган урман юлларының сыйфатламасы 1.1.9.1 таблицада китерелгән.

1.1.9.1 таблица

**Урман юлларына сыйфатлама**

| Юлларның төрләре | Юлларның озынлыгы, чм | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | урман хуҗалыгы (типлар буенча) | | | | агач ташу буенча | гомуми кулланылыштагы |
| | | 1 | 2 | 3 | Җәмгысе | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| Юллар, ш.и. барлыгы: | 367,2 | 15,6 | 58,8 | 260,3 | 334,7 | 1,1 | 31,4 |
| автомобиль: | 367,2 | 15,6 | 58,8 | 260,3 | 334,7 | 1,1 | 31,4 |
| каты түшәмәле | 15,4 | 3,1 | 0 | 0 | 3,1 | 0,1 | 12,2 |
| грунтлы, | 351,8 | 12,5 | 58,8 | 260,3 | 331,6 | 1,0 | 19,2 |
| ш.и. ел дәвамында хезмәт итүче | 139,1 | 2,6 | 10,6 | 109,4 | 122,6 | 1,0 | 15,5 |

Урман юлларының озынлыгы 367 чм, урман ызаннарыныкы – 650 чм.

Җирдән катнаш файдаланучылар белән бергә чикләрнең озынлыгы – 550 чм.

Кварталлардагы күрсәтмә баганаларның күләме – 700 данә. Бар булган урман инфраструктурасы объектларыннан агач кисеп салынган квартал юллары һәм җирдән катнаш файдаланучылар белән берлектәге чикләр 201 чм буена 280 данә күләмендә багана кисүне һәм чистартуны таләп итә.

1.1.9.2 Урман эшкәртү инфраструктурасы

Урман эшкәртү инфраструктурасы (әзерләнгән үзагачны, биоэнергетика объектларын һәм башкаларны эшкәртү объектлары) үзагач һәм башка урман ресурсларын эшкәртү өчен булдырыла. Россия Федерациясе Урман кодексының 14 статьясы нигезендә саклык урманнарында урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру тыела.

1.1.9.3 Урман инфраструктурасын булдыруга бәйле булмаган объектларны урман фонды җирләрендә Россия Федерациясе Урман кодексының 21 статьясына нигезләнеп төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү түбәндәгеләр өчен рөхсәт ителә:

1) җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләрне башкаруга;

2) файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгаруга;

3) сусаклагычларны һәм башка ясалма су объектларын, һәм шулай ук гидротехника корылмаларын һәм махсуслаштырылган портларны файдалануга;

4) электртапшыру линияләрен, элемтә линияләрен, юлларны, торбаүткәргечләрне һәм башка линияле объектларны файдалануга;

5) үзагач һәм башка урман ресурсларын эшкәртү;
6) рекреация эшчәнлеген башкаруга;
7) дини эшчәнлек башкару;

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару буенча эшләрне башкаруга бәйле объектлар, тиешле эшләрне башкару вакытлары тәмамланганнан соң җир асты турындагы законнар нигезендә консервацияләнергә яисә бетерелергә тиеш.

Гидротехника корылмалары су законнары нигезендә консервацияләнергә яисә бетерелергә тиешле.

Агачларны, куаклыкларны, лианаларны, шул исәптән гражданнарның иминлеген һәм тиешле объектларның эксплуатациясе өчен кирәкле шартларны булдыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән сак зоналарында һәм санитар-яклау зоналарында кисү түбәндәге максатларда рөхсәт ителә:

1) җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләрне башкаруга;
2) файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгаруга;
3) сусаклагычларны һәм башка ясалма су объектларын, һәм шулай ук гидротехника корылмаларын һәм махсуслаштырылган портларны файдалануга;
4) электртапшыру линияләрен, элемтә линияләрен, юлларны, торбаүткәргечләрне һәм башка линияле объектларны файдалануга;

Урман инфраструктурасын булдыруга бәйле булмаган объектларны төзү, реконструкцияләү һәм (яки) эксплуатацияләү буенча файдаланылган җирләр рекультивацияләнергә тиешле.

Урманчылык территориясендә урман инфраструктурасын булдыруга бәйле булмаган чираттагы объектлар бар:

ЛЭП – 224 чм;
газүткәргечләр – 2 чм;
бүтән трассалар – 71 чм;
нефтьүткәргечләр – 10 чм.

Бүлемтек юлыннан читтә үсүче һәм электрүткәргечләрнең һәм элемтә линияләренең үткәргечләренә яисә баганаларына авырга мөмкин булган аерым агачлар яисә агачлар төркеме үз вакытында киселергә тиеш. Электрүткәргечләргә һәм элемтә линияләренә (саклау зоналарына) якын булган урман авызларында комачаулаучы агачлар кичекмәстән киселә.

Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү урманнардан файдаланганда түбәндәге очраклар булмаска тиеш:

- бирелгән урман кишәрлегеннән читтә урман үсентеләрен, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;

- бирелгән урман кишәрлеген һәм бирелгән урман кишәрлеге чикләрендәге янәшә урнашкан территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;

- бирелгән урман кишәрлеге мәйданын һәм аның чикләрендәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;

- транспорт чараларының һәм бүтән механизмнарның бирелгән урман кишәрлеге читендәге юллардан гайре иректле маршрут буенча узарга.

Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү максатларында урманнардан файдаланучы затлар түбәндәгеләрне тәэмин итә:

- бирелгән урман кишәрлеген, аның янәшәсендәге урман аланнарын, ясалма һәм табигый су агып чыгу урыннарын төзелеш, урман кисү, көнкүреш һәм бүтән калдыклардан, агулы матдәләрдән даими рәвештә чистартып тора;

- эшчәнлек барышында бозылган юлларны, киптерү канауларын, дренаж системаларын, шлюзларны, күперләрне, башка гидротехника корылмаларын, квартал баганаларын, квартал юлларын торгыза;

- әлеге затлар гаебе белән барлыкка килгән һәлакәт очракларын, урман янгыннарын булдырмый калу, шулай ук башка шундый хәлләрне бетерү буенча кирәкле чаралар күрә.

Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдаланганда бозылган яисә пычранган җирләр тиешле эшләр тәмамланганнан соң кимендә бер ел эчендә рекультивацияләнергә тиеш. Электрүткәргечләр һәм элемтә линияләре трассаларының туфрак катламы эрозияне арттырырлык итеп бозылган барлык киңлеге буенча үләннәр чәчү һәм (яисә) куаклар утырту юлы белән рекультивация уздырылырга тиеш.

## 2.15. Урманнардан үзагач һәм башка урман ресурслары эшкәртү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Агач материалы һәм башка урман ресурслары әзерләү өчен урман кишәрлекләреннән файдалану РФ УК 46 ст. белән регламентлана, Татарстан Республикасының урман планы һәм урманчылыкның урман регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла. Урман эшкәртү объектларын урнаштыруның бүтән вариантлары булмаганда бүтән урман кишәрлекләреннән файдалану рөхсәт ителә.

Агач материалы һәм бүтән урман ресурсларын эшкәртү өчен урман инфраструктурасына бәйле булмаган объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү РФ УК ст. нигезендә рөхсәт ителә. Урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Үзагач һәм бүтән урман ресурсларын эшкәртү өчен арендага бирелгән урман кишәрлекләрендә урман эшкәртү инфраструктурасы булдырыла (әзерләнгән үзагачны эшкәртү объектлары, биоэнергетика объектлары һәм башкалар) (алга таба - урман эшкәртү инфраструктурасы объектлары)

Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын урнаштыру максатларында иң беренче чиратта урманныкы булмаган җирләр файдаланыла, ә урман кишәрлегендә мондый җирләр булмаганда – башланып та дәвам ителмәгән урман кисүләр җирләре, янгыннан соң калган җирләр, бушлыклар, ачыклыклар, шулай ук тулылыгы һәм кыйммәте түбән булган урман үсентеләре үсә торган җирләр.

Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын яклаучы урманнарда һәм махсус якланучы урманнарда урнаштыру рөхсәт ителми.

Үзагач һәм бүтән урман ресурсларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану кагыйдәләре “Үзагач һәм бүтән урман ресурсларын эшкәртү өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында” 12.12.2011 ел, №517 Рослесхоз боерыгында билгеләнә.

## 2.16. Урманнардан дини эшчәнлек өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм вакытлары

Урманнар дини оешмалар тарафыннан РФ УК 47 ст. һәм 1997 елның 26 сентябрендәге “Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында” №125-ФЗ

Федераль закон нигезендә дини эшчәнлек башкару буенча файдаланылырга мөмкин.

Дини эшчәнлек алып бару өчен бирелгән урман кишәрлекләрендә дини һәм хәйрия билгеләнешендәге биналар, корылмалар, төзелмәләр төзү рөхсәт ителә (РФ УК 47 ст. 2 өлеше).

Урманнардан әлеге файдалану, урман ресурсларын алмыйча гына, урман кишәрлекләрен биреп гамәлгә ашырыла.

Урман ресурсларын әзерләү һәм җыю, авыл хуҗалыгы һәм башка шундый эшчәнлек алып бару дини оешмалар тарафыннан бирелгән урман кишәрлекләрендә РФ УК бүтән статьялары нигезендә башкарылырга мөмкин.

Дини эшчәнлек алып бару өчен урманнардан файдалану субъектлары һәм тиешле урман кишәрлегенә мөлкәти хокуклары булган тиешле субъектлар дини оешмалар дип игълан ителә.

26.09.1997 ел, №125-ФЗ Федераль законның 8 статьясы нигезендә дини оешма дип Россия Федерациясе гражданнарының, Россия Федерациясе территориясендә даими һәм законлы нигезләрдә яшәүче бүтән затларның бергә гыйбадәт кылу һәм дин тарату максатларында төзелгән һәм юридик затлар буларак законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән ирекле берләшмәсе танызла.

Юридик зат статусына ия булмаган дини берләшмәләргә, шулай ук дини төркемнәргә һәм аларда катнашучыларга дини максатларда урманнарны файдалану өчен бирү каралмаган. Дини оешмалар 08.08.2001 ел, №129-ФЗ Федераль закон нигезендә дәүләт теркәве узарга тиеш (дини оешмаларның вөждан ирεге һәм дин тоту турындагы законнар белән билгеләнгән дәүләт теркәвен узу тәртибен исәпкә алып).

РФ УК 47 ст. 3 өлеше билгеләгәнчә, дәүләт яисә муниципаль милектәге урман кишәрлекләре дини оешмаларга дини эшчәнлек башкару өчен түләүсез сроклы файдалануга бирелә.

## 2.17. Урманнарны саклау, яклау, яңадан үстерүгә карата таләпләр

### 2.17.1. Урманнардагы янгын куркынычсызлыгы чараларына, урманнарны радиоактив матдәләрдән һәм бүтән тискәре йогынтыдан саклауга карата таләпләр

Урманнарны янгыннардан саклау РФ УК 51-53 статьялары, “Янгын куркынычсызлыгы турында” 21.12.1994 ел, №69-ФЗ Федераль закон, 30.06.2007 ел, №417 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Россия Федерациясе урманнарында янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре (алга таба – Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре урманнарны саклаганда, яклаганда һәм торгызганда, урманнарда бүтән эшчәнлек башкарганда урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә карата бердәм таләпләр урнаштыра һәм дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук юридик затлар һәм гражданнар өчен үтәлеше мәҗбүр була.

Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре һәр урман районы өчен Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

Урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

а) урманнарны янгынга каршы төзекләндерү, шул исәптән янгынга каршы юлларны, урманнарны яклау һәм саклау буенча авиация эшләре башкару максатларында самолетлар һәм вертолетлар өчен очып төшү мәйданчыклары төзү, реконструкцияләү һәм тоту, бүлемтек юллары салу, янгынга каршы аермалар казу;

б) урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү системаларын, чараларын булдыру, шушы системаларны һәм чараларны тоту, шулай ук янгын куркынычсызлыгы югары булган чорда ягулык-майлау материаллары запасларын формалаштыру;

в) урманнарда янгын куркынычын мониторинглау;

г) урман янгыннарын сүндерү планнарын эшләү;

д) урман янгыннарын сүндерү;

е) урманнарда янгын куркынычсызлыгы буенча башка чаралар.

Урманнарда янгын куркынычсызлыгының санап үтелгән чаралары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан аларның вәкаләтләре чикләрендә Россия Федерациясе Урман кодексының 81-84 статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарны янгынга каршы төзекләндерү, шул исәптән янгынга каршы юллар, урманнарны яклау һәм саклау буенча авиация эшләре башкару максатларында самолетлар һәм вертолетлар өчен очып төшү мәйданчыклары төзү, реконструкцияләү һәм тоту, бүлемтек юллары салу, янгынга каршы аермалар казу, шулай ук янгыннарны булдырмый калу һәм сүндерү системаларын, чараларын тоту, шулай ук янгын куркынычсызлыгы югары булган чорда арендага бирелгән урман кишәрлекләрендә ягулык-майлау материаллары запасларын формалаштыру урманнарны үзләштерү проекты нигезендә шушы урман кишәрлекләренең арендаторлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Урманнарда янгын куркынычсызлыгының гомуми таләпләре.

Кар катламы эреп беткәннән алып тотрыклы яңгырлы көзге көннәр урнашканчы яисә кар катламы барлыкка килгәнче урманнарда түбәндәгеләр тыела:

а) ылыслы яшь урманнарда, янгыннан соң калган урыннарда, зарарланган урман кишәрлекләрендә, торфянникларда, кисек калдыкларыннан һәм әзерләнгән агач материалыннан чистартылмаган урманнар кискән урыннарда (урман бүлемтекләрендә), кипкән үләннәр мәйданнарында, шулай ук агачлар ябалдашлары асларында учак ягарга. ябалдашлары асларында учак ягарга. Башка урыннарда учак ягу кимендә 0,5 метр киңлектәге минеральләштерелгән полоса белән уратып алынган (ягъни туфракның минераль катламына кадәр чистартылган) мәйданчыкларда рөхсәт ителә. Кисек калдыкларын яндыру тәмамланганнан яисә учакны башка максатта файдаланганнан соң учак урынын әйбәтләп туфрак белән күмәргә яисә учак тәмам сүнгәнче су сибәргә кирәк;

б) янып торган шырпы, тәмәке төпчекләре һәм тәмәке төрепкәсеннән көл, пыяла (пыяла шешәләр, банкалар һәм башкалар) ташларга;

в) ау вакытында ягулык яисә пыскып торучы материаллардан тыккычлар кулланырга;

г) бензин, керосин яисә башка ягулык матдәләре сеңгән материалларны (кәгазь, тукыма, пәҗи, мамык һәм башкалар) шуның өчен махсус каралмаган урыннарда калдырырга;

д) двигатель эшләп торганда эчке янулы двигательләр бакларына ягулык салырга, туклану системасы төзек булмаган двигательле машиналардан файдаланырга, шулай урман кишәрлекләре ягулык салына торган машиналар янәшәсендә тәмәке тартырга яисә ачык уттан файдаланырга.

Урманнарны көнкүреш, төзелеш һәм бүтән төрле калдыклар белән чүпләү тыела.

Торак пунктыннан чыгарылган чүпне яндыру урман янәшәсендә бары тик махсус билгеләнгән урыннарда гына түбәндәге шартлар булганда рөхсәт ителә:

а) чүп яндыру урыннары (котлованнар яисә мәйданчыклар) кимендә түбәндәге ераклыкта урнашырга тиеш:

- ылыслы урманнан яисә аерым үсеп утыручы ылыслы агачлардан һәм яшь агачлардан – 100 метр;

- яфраклы урманнан яисә аерым үсеп утыручы яфраклы агачлардан һәм яшь агачлардан – 50 метр;

б) чүп яндыру урыны тирәсендәге территория (котлованнар яисә мәйданчыклар) 25-30 метр радиуста корыган агачлардан, ауган агачлардан, кисек калдыкларыннан, башка ягулык материалларыннан чистартылган һәм һәрберсенең киңлеге кимендә 1,4 метр булган ике катлы минеральләштерелгән полосалар белән әйләндереп алынган булырга, ә коры туфраклардагы ылыслы урман янәшәсендә һәрберсенең киңлеге кимендә 2,6 метр, аралары 5 метр булган ике катлы минеральләштерелгән полосалар белән әйләндереп алынган булырга тиеш.

Урманнарда янгын куркынычы сезонында чүп яндыру бары тик яраклы һава торышы булганда һәм җаваплы затлар контролендә генә рөхсәт ителә.

Урманнарга, яклаучы һәм яшелләндерү урман үсентеләренә якын җир кишәрлекләрендә даими күзәтүдән башка үлән яндыру тыела.

Урманнардан файдаланучы юридик затларның һәм гражданнарның бурычлары түбәндәгеләр:

а) ягулык-майлау материалларын ябык савытта саклау, янгын куркынычы сезонында аларны саклау урыннарын үлән катламыннан, агач материалы чүбеннән, башка ягулык материалларыннан чистарту һәм аларны 1,4 метр булган минеральләштерелгән полоса белән әйләндереп алу;

б) шартлаткыч матдәләр ярдәмендә түмәрләрне казып чыгарганда шушы эшләрне башкару хакында тиешле дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына аларны башлаганчы кимендә 10 көн кала хәбәр итәргә; урманда янгын куркынычы зур булганда әлеге матдәләр ярдәмендә түмәрләрне казып чыгаруны туктатырга тиеш;

в) Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан расланган урманнардан файдалану урыннарында янгын сүндерү чараларын булдыру нормаларын үтәргә, янгын куркынычы югары булган чорда янгын сүндерү чараларын аларны кичекмәстән кулланырлык итеп әзер килеш тотарга;

г) үзләре гаебе белән чыккан урман янгыннарын сүндерергә;

д) урманнардан файдалану урыннарында чыккан урман янгыннарын сүндерү буенча кичекмәстән чаралар күрергә, шулай ук янгын турында тиешле дәүләт хакимияте органнарына яисә җирле үзидарә органнарына хәбәр итәргә;

е) хезмәткәрләрне (юридик затлар өчен), янгын техникасын, транспорт һәм башка чараларны Россия Федерациясе законнары нигезендә янгын сүндерүгә җибәрергә.

Янгын куркынычы югары булган чор башланганчы урманнардан файдаланучы юридик затлар үз хезмәткәрләренә, шулай ук алар уздыра торган массакүләм чараларда катнашучыларга янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү, шулай ук урман янгыннарын сүндерү алымнары турында инструктаж уздырырга тиеш.

Янгын куркынычы класслары буенча урманчылык мәйданын бүлү 2.17.1.1 таблицада китерелә.

2.17.1.1 таблица

**Янгын куркынычы класслары буенча урманчылык мәйданын бүлү**

мәйданы, га

| № п/п | Кишәрлек урманчылыгы | Янгын куркынычы классы | | | | | Җәмгысе | Уртача класс |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 1. | Биклән | 2274 | 277 | 902 | 4957 | - | 8410 | 3,0 |
| 2. | Кызыл Юл | 1222 | 890 | 6915 | - | 9027 | 9027 | 2,6 |
| 3. | Баграж | 369 | - | 2563 | 5941 | - | 8873 | 3,6 |
| 4. | Ворошилов | 92 | 256 | 802 | 5302 | - | 6452 | 3,7 |
| 5. | Ләке | 358 | 481 | 4794 | 4731 | - | 10364 | 3,3 |
| | Урманчылык буенча җәмгысе: | 4310 | 1924 | 15980 | 21272 | - | 43486 | 3,2 |

2011 елның 5 июлендәге “Урманнарның табигый янгын куркынычы классификациясен һәм һава шартларына бәйле рәвештә урманнарда янгын куркынычы классификациясен раслау турында” №287 Рослесхоз боерыгы нигезендә урман янгыннары чыгу дәрәҗәсе бәяләнде.

Шкала, токым составы үзенчәлекләрен, туфрак дымлылыгын, урман үсентеләренең яшен һәм торышын исәпкә алып, туфрак-типологик принцип буенча төзелде.

Янгын куркынычының уртача классы тулаем алганда – 3,2

2.17.1.2 таблица

**Урманнарның табигый янгын куркынычы классификациясе**

| Урманнарның табигый янгын куркынычы классификациясе | Янып китүчән объект (кисүләрдән соң урманнарның, урман утыртмаларының һәм урмансыз киңлекләрнең характерлы типлары) | Янгыннарның иң күп мөмкин булган төрләре һәм алар чыгуның һәм таралуның мөмкин чоры |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| I (бик югары табигый янгын куркынычы) | Ылыслы яшь агачлар Тоташ кисү урыннары: мүкле, арчанлы, кылганлы һәм коры урыннар буенча кисүләр (бигрәк тә чүпләнгән).<br>Мүкле һәм арчанлы наратлыклар.<br>Зәгыйфьләнгән, корып баручы һәм бик зарарланган агачлыклар (корыган агачлар, җил-буран аударган урыннар, кисеп бетермәгән урыннар), аерым агачлар калдырып, тоташ кисү урыннары, югары һәм бик югары интенсивлыктагы сайлап алып кисүләр урыннары, чүпләнгән элек янган урыннар. | Янгын куркынычы югары булган чор дәвамында – аскы өлештә, агачлар булган җирләрдә өске өлештә булырга мөмкин.<br>Кылганлы һәм башка үләннәр үскән коры урыннардагы урман кисүләрдә янгын куркынычы – бигрәк тә яз көне, ә кайбер районнарда көз көне дә югары була. |
| II (табигый янгын куркынычы - югары) | Нарат җиләкле, нарат шытымнары яисә уртача куелыктагы артыш куаклыклары булган наратлыкларда.<br>Кедрлы-стланниклы яфраклылар. | Янгын куркынычы югары булган чор дәвамында аскы өлештә; өске өлештә – янгыннар максимумнары чорында (янгын чыгу саны яисә янгын элеп алган мәйдан әлеге район өчен күпьеллык күрсәткечләрдән артып китә торган чор дәвамында). |
| III (табигый янгын куркынычы - уртача) | Ачы җиләкле наратлыклар һәм кара җиләклекләр, нарат җиләкле яфраклылар, барлык типтагы кедрлыклар, сфагналы, нарат җиләкле чыршылыклар һәм ачы җиләклекләр. | Аскы һәм өске янгыннар җәйге максимум чорында булырга мөмкин, ә кедрлыкларда, моннан тыш, язгы һәм бигрәк тә көзге максимумнарда. |
| IV (табигый янгын куркынычы - аз) | Тубылгылы һәм озын мүкле тоташ кисү урыннар (бигрәк тә чүпләнгән).<br>Үләнле типтагы урманнарда наратлыклар, яфраклылар һәм яфраклы урман үсентеләре.<br>Катлаулы наратлыклар һәм чыршылыклар, юкәлекләр, чикләвеклекләр, имәнлекләр, чыршылыклар-кара җиләклекләр, сфагналы һәм озын мүкле чыршылыклар һәм елга буйларындагы һәм сфагналы кедрлыклар, каенлыклар-мүк җиләклекләр, ачы җиләклекләр, кара җиләклекләр һәм сфагналы, усаклыклар-ачы җиләклекләр һәм кара җиләклекләр, мари. | Янгыннар чыгу (беренче чиратта аскы) үләнле типтагы урманнарда, тубылгылы һәм озын мүкле кисү урыннарында язгы һәм көзге масимумнар чорында; башка тип урманнарда һәм озын мүкле кисүләрдә җәйге максимум чорында мөмкин. |

| Урманнарның табигый янгын куркынычы классификациясе | Янып китүчән объект (кисүләрдән соң урманнарның, урман утыртмаларының һәм урмансыз киңлекләрнең характерлы типлары) | Янгыннарның иң күп мөмкин булган төрләре һәм алар чыгуның һәм таралуның мөмкин чоры |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| V (табигый янгын куркынычы - юк) | Чыршылыклар, каенлыклар һәм усаклыклар, озын мүклекләр, сфагнумлы һәм елга буйларындагы чыршылыклар. Барлык типтагы зиреклекләр. | Янгын бары тик аеруча начар шартларда (дәвамлы корылык) гына чыгарга мөмкин. |

Искәрмәләр: Янгын куркынычы түбәндәге урманнар өчен бер класска югарырак билгеләнә:

- төзелеше яисә бөтән үзенчәлекләре аскы янгын кинәт кенә өске янгынга күчү мөмкинлеге булган ылыслы урман үсентеләре өчен (ылыслы агачларның биек куе шытымнары булган токымнары, агачларның һәм куакларның ябалдашлары вертикаль рәвештә ябылган урман үсентеләре, шактый гына чүпләнү һәм башкалар);

- янгын куркынычы югары булган урман үсентеләре белән әйләндереп алынган коры урыннарда зур булмаган урман кишәрлекләрендә;

- гомуми файдаланудагы автомобиль юллары һәм тимер юллар янәшәсендәге урман кишәрлекләре өчен.

Куе шытымнары булган яисә ябалдашлары вертикаль рәвештә ябылган кедрлыклар II класслы янгын куркынычына кертелә.

Һава шартларына карап урманнардагы янгын куркынычы классификациясе

1. Һава торышына карап, урманнарда янгын куркынычын классификацияләү урманнарның янгын куркынычына йогынты ясый торган метеорологик шартларга карап, тиешле территориядә урман янгыннары чыгу (мөмкинлеге) дәрәҗәсен билгели.

2. Классификацияләү (бәяләү) максатлары өчен метеорологик (һава торышы) шартларын характерлый торган комплекслы күрсәткеч кулланыла.

3. Комплекслы күрсәткеч зурлыгына карап, урманнарда һава торышына бәйле рәвештә янгын куркынычы классы билгеләнә.

Комплекслы күрсәткеч һәр көн саен 12-14 сәгатьләрдә билгеләнә.

Россия Федерациясе субъектларында һава торышына карап, урманнарда янгын куркынычының региональ класслары (алага таба – региональ класслар) түбәндәгеләрне билгели:

- комплекслы күрсәткечне исәпләп чыгару методикасын;
- янгын куркынычы классы чикләрен;
- явым-төшемнәрне исәпләп чыгару методикасын.

Региональ классларны куллану турындагы карар Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы боерыгы буларак рәсмиләштерелә һәм төрле вакытлар өчен аерым-аерым билгеләнергә мөмкин.

5. Региональ класслар билгеләнмәгән регионнар өчен һава торышына карап урманнарда янгын куркынычының таблицада күрсәтелгән федераль класслары билгеләнә.

6. 6. Һава торышына карап урманнарда табигый янгын куркынычы классын исәпләп чыгару формуласы һава температурасын (t°) һава температураларының һәм яңгырсыз n көн эчендә чык ноктасының (эта) аермасына тапкырчыгышы суммасы рәвешендә билгеләнә (яңгырсыз чорда 3 мм дан артыграк явым-төшем төшкән көнне беренче көн дип санап):

$$
\text{КП} = \text{SUM}\left[t^{\circ}\,(t^{\circ} - \text{ул})\right]\frac{1}{N}
$$

2.17.1.3 таблица

**Һава торышы буенча урманнардагы янгын куркынычы күрсәткечләренә карап, урманнарда янгын куркынычсызлыгы чаралары**

| Урманнарда янгын куркынычы классификациясе | Комплекслы күрсәткеч зурлыгы | Янгын куркынычы дәрәҗәсе |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| I | 0 … 300 | Юк |
| II | 301 … 1000 | Аз |
| III | 1001 … 4000 | Уртача |
| IV | 4001 … 10000 | Югары |
| V | 10000 артык | Гадәттән тыш |

2012 елның 27 апрелендәге “Урманнарны янгынга каршы кору нормативларын раслау турында” №174 Рослесхоз боерыгына таянып, регламентта, табигый һәм икътисадый шартларны, урманнарның янып китүчәнлеге сыйфатламаларын, потенциаль ут чыганакларын исәпкә алып, янгынга каршы чаралар комплексы билгеләнә.

Урманнарны янгынга каршы төзекләндерү чараларына түбәндәгеләр кертелә:

- урман юлларын чистарту, аларның янгынга каршы минеральләштерелгән полосаларын яңарту;
- янгынга каршы сулыкларны һәм су белән тәэмин итү чыганакларына килү юлларын эксплуатацияләү;
- урманнарда гражданнар ял итә торган зоналарны төзекләндерү;
- шлагбаумнар кую һәм эксплуатацияләү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, урманнарда гражданнарның булуын чикләүне тәэмин итәрлек киртәләр кору;
- янгынга каршы киртәләр булдыру һәм тоту, яраклы урман авызларын төзекләндерү;
- урманнарда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүматы булган стендларны һәм башка тамгаларны урнаштыру.

Янгынга каршы кору чараларының ел саен булдырыла торган чаралар күләме 2.17.1.4 таблицада китерелгән.

2.17.1.4 таблица

**Янгынга каршы корулар буенча ел саен булдырыла торган чаралар күләме**

| № п/п | Чараларның исеме | Үлчәү берәмлеге | Таләп ителүче күләм |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | **1. Кисәтү чаралары** | | |
| 1.1 | Даими күргәзмәләр һәм витриналар | данә | 6 |
| 1.2 | Даими элмә такталар | данә | 6 |
| 1.3 | Кисәткеч аншлаглар | данә | 25 |
| 1.4 | Авыл хуҗалыгы оешмалары вәкилләре белән киңәшмәләр | данә | Кирәк булган саен даими |
| 1.5 | Шлагбаумнар урнаштыру | данә | 30 |
| 1.6 | Контроль постларын оештыру | данә | 12 |
| 1.7 | Ял һәм тәмәке тарту урыннарын оештыру | данә | 20 |
| 1.8 | Массачыл ял итү урыннарында аншлаглар урнаштыру | данә | 20 |
| | **2. Янгыннар таралуны чикләү буенча чаралар** | | |
| 2.1 | Янгынга каршы киртәләр, чокырлар булдыру | чм | 10 |
| 2.2 | Яфраклы токымнардан полосалар булдыру | чм | 40 |
| 2.3 | Культуралар, ылыслы яшь урманлыклар тирәли һәм юллар буйларында минеральләштерелгән полосалар кору | чм | 40 |
| 2.4 | Минеральләштерелгән полосаларны карап тору | чм | 219 |
| 2.5 | Урман ызаннары буйлап минеральләштерелгән полосалар кору | чм | 100 |
| | **3. Юл төзелеше** | | |
| 3.1 | Янгынга каршы юллар төзү | чм | 1 |
| 3.2 | Күперләр төзелеше | данә | 5 |
| 3.3 | Янгынга каршы билгеләнештәге юлларны төзекләндерү | чм | 25 |
| 3.4 | Күперләрне төзекләндерү | данә | 1 |
| | **4. Элемтә оештыру** | | |
| 4.1 | Телефон нокталарын урнаштыру | нокт. | 6 |
| 4.2 | Радиостанцияләр (кәрәзле элемтә) булдыру | данә | 10 |
| 4.3 | Элемтә линияләрен төзекләндерү | чм | 50 |
| | **5. Күзәтчелек-сак хезмәте** | | |
| 5.1 | Янгын вышкалары төзү | данә | 2 |
| 5.2 | Янгынга каршы вакытлы каравылчылар яллау | кеше | 20 |
| 5.3 | 2 ф. йортлар төзү | данә | 1 |
| | **6. Янгыннарга каршы көрәш чаралары** | | |
| 6.1 | Янгын сүндерү инвертарьләре пунктларын оештыру | пункт | 6 |
| 6.2 | ИЯД булдыру | күләме | 6 |
| | **7. Янгыннаргы каршы кораллар сатып алу** | | |
| 7.1 | Урман-янгын сүндерү автомашинасы | данә | 2 |
| 7.2 | Кече урманпатруль комплексы КУПК | данә | 5 |
| 7.3 | Күчмә җиһазландырылган мотопомпалар (МН-13\60 һ.б.) яки кечкенә габаритлы (МЛН-3\0,3 Л- | данә | 2 |

| №<br>п/п | Чараларның исеме | Үлчәү берәмлеге | Таләп ителүче күләм |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | 1\0,75,МЛВ-1,МЛВ-2,МЛП-0,2 һ.б.) | | |
| 7.4 | Су куа торган җиңсәләр (Д - 26, 51, 66 мм) | пог.м | 600 |
| 7.5 | Ут кабыза торган җайланмалар (АЗ һ.б.) | данә | 2 |
| 7.6 | Бензопычкылар | данә | 6 |
| **8.** | **Кул инструментлары:** | | |
| 8.1 | Тимер тырмалар | данә | 50 |
| 8.2 | Көрәкләр | данә | 50 |
| 8.3 | Балталар | данә | 50 |
| 8.4 | Эчәр су өчен бидоннар яисә канистрлар | данә | 10 |
| 8.5 | Су өчен тимер чиләкләр | данә | 10 |
| 8.6 | Су өчен кружкалар | данә | 15 |
| 8.7 | Кизү торучыга махсус кием (итекләр, куртка, чалбар, бияләйләр) | данә | Янгын сүндерү буенча даими команда әгъзалары санына карап |
| 8.8 | Саклагыч күзлекләр, респираторлар | данә | Янгын сүндерү буенча даими команда әгъзалары санына карап |
| 8.9 | Беренче ярдәм күрсәтү буенча медицина аптечкасы | данә | 10 |
| 8.10 | Индивидуаль яра бәйләү пакетлары | данә | 20 |

Урманнарны янгыннардан саклаганда эш урыннарын урнаштыру һәм планлаштыру нормативлары 2.17.1.5 таблицада китерелгән.

2.17.1.5 таблица

**Урманнарны янгыннардан саклаганда эш урыннарын урнаштыру һәм планлаштыру нормативлары**

| №<br>п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар<br>(оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Гомуми нормативлар: | |
| 1.1 | Шәһәр урманнарын урман янгыннары районнарына бүлү: | |
| | җир өстендәге сак районнары | янгыннарны ачыклау һәм сүндерү җир өсте чаралары белән гамәлгә ашырыла |
| 1.2 | Янгын куркынычлылыгы дәрәҗәсе буенча урман фонды кишәрлекләрен бәяләү: | |
| | югары уртача<br>түбән | үсеп китү урыны шартлары буенча -<br>1 - 2 класслар, һава шартларына карап -<br>4 - 5 класслар, 3 класс |
| 1.3 | Урманнарның фактта яну чоры (янгын куркынычы тудыручы һава торышы чоры) | Һава торышы буенча янгын куркынычының 2 - 5 класслы көннәре |

| № п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1.4 | Урманчылык буенча янгын куркынычы сезонының факттагы озынлыгын билгеләү | Кар катламы кузгалу һәм барлыкка килү. 10 ел һәм аннан да күбрәк еллар эчендә урманнарның фактта яну чорының максималь һәм уртача чоры озынлыгы. Җирле шкалалар буенча һава торышының янгын куркынычы дәрәҗәсе – һава торышының 2 класслы янгын куркынычы башлану һәм бетүнең иң соңгы һәм уртача даталары |
| 1.5 | Урманнарның чагыштырмача янучанлыгы | Янгыннарның уртача еллык мәйданын урман фонды мәйданына бүлүдән килеп чыккан зурлык |
| 1.6 | Урман янгыннарының зурлыгы:<br>эре<br>исәпкә алып була торган | 25 гектардан зуррак мәйдан<br>теләсә нинди мәйданда урман фонды территориясе янып китү |
| 1.7 | Янгынның интенсивлыгы<br>түбән уртача югары | ялкынның биеклеге 0,5 м һәм аннан да югары<br>ялкынның биеклеге 0,6 - 1,0 метр<br>1,0 метрлан биегрәк |
| 2 | Җир өстендәге сак районнарында урманнарны янгынга каршы планлаштыру нормативлары: | |
| 2.1 | Ылыслы токымнарның янгын куркынычы булган эре массивларын планлаштыру | Ылыслы токымнарның янгын куркынычы булган эре массивларын планлаштыру 2 гектардан алып 12 мең гектарга кадәр мәйданда өске һәм аскы янгыннар таралуга каршы торырлык (янгын куркынычы дәрәҗәсенә һәм урман хуҗалыгы интенсивлыгына бәйле рәвештә) янгынга каршы табигый яисә ясалма барьерлар яисә аермалар белән, шулай ук гамәлдәге янгыннарны локальләштергәндә таяныч линияләре белән эре йомык блокларга бүлү. Аларда гомуми юллар челтәренә керерлек юллар салалар. |
| 2.2 | Урман массивлары территориясендә янгынга каршы табигый киртәләр сайлау | Су баса торган киң тугайлы күлләр һәм елгалар, яфраклылар өстенлек иткән урман кишәрлекләре (составы буенча кимендә 7 берәмлек), урманнар һәм янучан материаллар белән капламаган кишәрлекләр |
| 2.3 | Янгынга каршы ясалма киртәләр һәм чокырлар сайлап алу | Мөмкинлек булган саен һәр ягы буйлап 50 - 60 метр киңлектә яфраклы агачлыклардан полосалар булдырыла торган тимер һәм автомобиль юллары трассалары, электртапшыру линияләре, торбаүткәргечләр һ.б.ш. Киртәнең гомуми киңлеге - 120 - 150 метр. Яфраклы полосаларның урманга карап торучы тышкы яклары буйлап 1,4 метр киңлектәге минеральләштерелгән полосалар , ә әгәр дә яфраклы полосалар янгын куркынычы буенча 1 һәм 2 классларга караган урыннарга тоташса, бер-берсеннән 5 - 10 метр ераклыкта ике минеральләштерелгән полоса булдырыла. Яфраклылар полосалары булдыру мөмкин булмаган ылыслы урман утыртмалары территориясе (урманчылык сәбәпле) чокырның һәр ягыннан киңлеге 120-150 м булган полосаларда янучан материаллардан (агач материалы чүбеннән, ылыслы шытымнардан, янгын куркынычы |

| №<br>п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар<br>(оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | булган урманчыклардан, ылыслыларның 1,5-2,0 метрга кадәрле аскы ботакларыннан һәм башкалардан) даими рәвештә чистартылып торыла. Ылыслы урманның мондый полосаларын янәшәдәге урманнан чиклиләр һәм буеннан буена һәр 20 - 30 метр аша 1,4 метр киңлектәге минеральләштерелгән полосалар белән аерылар. Мондый төп каплавычларның гомуми киңлеге (чокырның яисә юлның киңлеге белән берлектә) - 260 - 320 метр. |
| 2.4 | Янгынга каршы өстәмә киртәләр һәм чокырлар булдыру | 2.2 һәм 2.3 пунктларда күрсәтелгән киртәләр тиешле күләмдә булмаган очракта, блок буйлатып йомык боҗра булдыру өчен аларда юллар һәм һәр ике як буйлап яфраклы полосалар булдырып чокырлар казыйлар |
| 2.5 | Уртача интенсивтагы урман хуҗалыгы алып барыла торган зоналарда урнашкан, янып китүчәнлеге югары булган ылыслыларның кыйммәтле токымнары массивларында планлаштыру | 2-12 мең га (әлеге таблицаның 2.1 пунктын кар.) кадәр мәйданлы эре блокларны һәм массивларны 2.2-2.4 пунктларда каралган тәртиптә 400дән 1600 га кадәр мәйданлы уртача йомык блокларга (чокырларга, уттан каплавычларга) бүләләр. Шул ук вакытта киң кулланылыштагы (тимер юл, шоссе) юлларның һәр ягы буенча яфраклы полосаларны (хуҗалар көче белән) 30 - 50 метр киңлектә, ә башка чокырлар, шул исәптән кварталлардагы урман юллары буйлап һәр ягыннан 10 -15 метр киңлектә булдыралар. Ылыслы яшь агачлыклар булган чокырларга тоташучы аеруча кыйммәтле массивларда (яфраклы полосаларны булдыру мөмкинлеге булмаганда) һәр яктан 100 метр киңлектәге полосаларны янучан материаллардан чистарталар һәм, әлеге таблицаның 2.3 пунктында күрсәтелгәнчә, һәр 20-30 метр саен буйлы минеральләштерелгән полосалар ясыйлар. Мондый эчке (өстәмә) яфраклы токым саклагычларының киңлеге 60 - 100 метр булырга тиеш, ылыслы токымнарныкы - 200 метр, урман юллары буенча (чокырларның һәм урман юлларының киңлеген исәпкә алмыйча) - 20 - 30 метр. |
| 2.6 | Яшел зоналарда һәм 1 класслы ылыслы культураларның һәм яшь урман үсентеләренең эре кишәрлекләрен планлаштыру | Аларны 25 гектар мәйданлы блокларга минеральләштерелгән полосалар яисә юллар ярдәмендә бүләләр, һәр тарафыннан яфраклы яшь агачлардан һәм куаклардан 10 метр киңлектәге полосалар булдыралар. Аның үзәгеннән гади юл белән каплавычның гомуми киңлеге - 30 метр. Яфраклы полосаларны булдыру мөмкин булмаганда, 100 метр киңлектәге полосалардагы ылыслылар чокырына якын урыннарда һәрьяклап янучан материалны юк итәргә, шулай ук 20-30 метр саен аркылы минеральләштерелгән полосалар салырга кирәк (әлеге таблицаның 2.3 пунктын кар.) |
| 2.7 | Поселоклар янәшәсендәге ылыслы урманнарны планлаштыру | Урман массивы тирәли янгынга чыдам булган кимендә 150 метр киңлектәге яфраклы кырпулар булдыралар. Мондый кырпуларның һәр тарафында кимендә 2,5 метр киңлектәге минеральләштерелгән полосалар булдыралар. Әгәр дә яфраклы кырпуларны булдыру мөмкин булмаса, |

| №<br>п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар<br>(оптималь күрсәткечләр) | |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | |
| | | ул очракта поселокка тоташучы ылыслы урман полосаларында 250 - 300 метрлы киңлектә янучан материалларны юк итәләр һәм алар буйлап һәр 50 метр саен буйлы минеральләштерелгән полосалар салалар (әлеге таблицаның 2,3 пунктын кар.) | |
| 2.8 | Минеральләштерелгән саклык полосаларын бульдозерлар, тракторлар, туфрак эшкәртүче һәм башка кораллар ярдәмендә туфрак өстендәге каплам төренә һәм куәтенә бәйле рәвештә салганда: | | |
| | куәтле үлән капламында һәм чүпләнгән урыннарда җиләклекләрдән һәм арчаннан лишайниклардан һәм яшел мүкләрдән | 1,0 дән 1,5 метрга кадәр<br><br>1,5 дән 2,5 метрга кадәр<br>2,5 дән 4,0 метрга кадәр<br>1,4 метр (ПКЛ-70 сукасы бер тапкыр уза) | полосаның киңлеге түбәнлектәге янгын ялкынының мөмкин булган биеклегеннән ике тапкырга артыграк булу хисабыннан чигереп тору сыйфатында хезмәт итәргә мөмкиннәр |
| | блокларның һәм ылыслы массивларның эчендә минималь киңлек (әлеге таблицаның 2.1, 2.5 - 2.7 пунктлары) | корылмалар, урман культуралары, табигый шытып чыккан урманнар булган мәйданнар тирәсендә, ылыслы, яфраклы урман үсентеләрендә уза торган агач ташу юллары буйларында, минеральләштерелгән полосаларның дәвамы буларак булдырылган янгынга каршы киртәләрдә һәм ылыслы утыртмаларда, шулай ук кирәк булган башка урыннарда | |
| | янгын куркынычы булган сезонга калдырылган коры туфракларда урнашкан ылыслы тигез урманнардагы коры туфраклы диләнкеләрдә | урман әзерләүчеләр көче белән диләнкеләр минеральләштерелгән полосалар белән әйләндереп алына. 25 гектардан артык мәйданлы диләнкеләрне аркылы минеральләштерелгән полосалар белән 25 гектардан артмаган кишәрлекләргә бүләләр. Үзагачны саклыкка кую урыннары шулай ук аерым, йомык минеральләштерелгән полосалар белән әйләндереп алына, ә ылыслы урманнарны кисү урыннарында – бер-береннән 5-10 метр ераклыкта булган ике шундый полоса белән әйләндереп алына | |
| | тимер юлларда, шосселарда һәм агач ташу юлларында (үз карамакларындагы оешмалар көчләре белән) | алар буйларындагы полосалар (агач ташу өчен – һәр ягыннан 10 метр) янгын сезоны эчендә ауган агачлардан, агач чүпләреннән һәм башка тиз кабынып китүчән материаллардан чистартып торыла.<br>Минеральләштерелгән полосаларны чигерелгән полосаларның тышкы ягы буйлап салалар, ылыслы утыртмаларда коры туфракта - бер-берсеннән 5 метр ераклыкта ике минеральләштерелгән полоса салына.<br>Шушындый ук шартларда минполосалар белән юл буйларында яткан шпаллар өемнәрен һәм кар саклау щитларын, агач күперләрне, стационар платформаларны, торак йортларны һәм юлларны карап йөрүчеләр будкаларын әйләндереп алалар, учак ягу рөхсәт ителгән урыннар, урманда ял итү һәм тәмәке тарту урыннары, урманнарда эшләр башкарганда ЯММ саклау урыннары тирәли, янгын куркынычы урман промыселлары мәйданчыклары тирәли (күмер ягу, сагыз, дегет эшкәртү | |

<table>
<tr><th>№<br>п/п</th><th>Күрсәткечләр</th><th colspan="2">Нормативлар<br>(оптималь күрсәткечләр)</th></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td colspan="2">3</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td colspan="2">һәм башкалар), арадаш һәм төп чәер складлары тирәли, авыл хуҗалыгы җирләре чикләре буйлап әйләндереп алалар</td></tr>
<tr><td rowspan="2">2.9</td><td colspan="3">Янгын куркынычы сезонында янгынга каршы аермалар кору:</td></tr>
<tr><td>урмандагы үзагач саклыкханәләре тирәли</td><td colspan="2">саклыкханәләрне ачык урыннарда түбәндәге аралыкта урнаштыралар: яфраклы урман диварларыннан складлаштыру урыннары мәйданы 8 га - 20 м кадәр, 8 га һәм аннан да күбрәк - 30 м, ылыслы һәм катнаш урман диварларыннан складлаштыру урыннары мәйданы 8 га - 40 м, 8 га аннан да күбрәк - 60 м.<br>саклыкка кую урыннары һәм күрсәтелгән янгынга каршы чокырлар янучан материаллардан чистартыла</td></tr>
<tr><td>2.10</td><td colspan="3">Янгынга каршы сулыклар кору: урман янгыннары чыгу мөмкин булган урыннан ерак урнашкан су чыганакларын урнаштыру:</td></tr>
<tr><td rowspan="7"></td><td>утыртмаларның янгын куркынычы классификациясе</td><td>ераклыгы, чм</td><td>бер сулыктан су белән тәэмин ителүче утыртмалар мәйданы, га</td></tr>
<tr><td>1</td><td>2-4</td><td>500</td></tr>
<tr><td>2</td><td>2-8</td><td>2000-5000</td></tr>
<tr><td>3-5</td><td>8-12</td><td>5000-10000</td></tr>
<tr><td>янгын сүндерү өчен табигый су чыганакларын әзерләү</td><td colspan="2">аларга килү юлларын төзекләндерү, янгын автоцистерналары һәм мотопомпалар белән су алу өчен махсус мәйданчыклар җиһазландыру, ә кирәк очракларда сулыкларны тирәнәйтү һәм буалау</td></tr>
<tr><td>янгын сүндерү буенча ясалма сулыклар төзү</td><td colspan="2">янгын куркынычы югары булган урман массивларында, аларда табигый су чыганаклары булмаганда, яхшыртылган автомобиль юллары янында, алардан сулыкларга кадәр килү юллары салына</td></tr>
<tr><td>янгынга каршы сулыкта нәтиҗәле су запасы</td><td colspan="2">елның иң эссе чорында кимендә 100 кубометр</td></tr>
<tr><td rowspan="2">2.11</td><td colspan="3">Урман юлларын кору:</td></tr>
<tr><td>юл челтәрләренең гомуми тыгызлыгы (куелыгы)</td><td colspan="2">Кимендә 6 чакрым - 1000 гектар гомуми мәйданга, шул исәптән янгын куркынычы түбән булган һәм янгын тиз таралмый торган урман үсентеләре өстенлек иткән кварталларда юллар челтәре куелыгы 6 км/мең гектар рөхсәт ителә, янгын куркынычы югары булган урман үсентеләре өстенлек иткән кварталларда ул бу күрсәткечтән артык булырга тиеш</td></tr>
<tr><td></td><td>урман хуҗалыгы юллары</td><td colspan="2">урман янгыннары белән көрәш өчен түгел, урман хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен кирәкле юллары булган кишәрлекләрдә урман хуҗалыгы интенсив алып барыла торган үзләштерелгән урманнарда корыла. 5 категория гомуми файдаланудагы юлларга тиңләштерелә һәм 3 типка бүленә.<br>1 тип урман хуҗалыгы юллары:<br>бер полосалы, полосаларның гомуми киңлеге - 8 метр, юл кырые киңлеге – 1,75 метр.</td></tr>
</table>

| №<br>п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар<br>(оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | Исәпләп чыгарылган хәрәкәт тизлеге - 60 чм/сәг, сикәлтәле урыннарда 40 чм/сәг кадәр кими |
| | янгынга каршы юллар | 3 типлы урман хуҗалыгы юлларына керә, җир капламының киңлеге 4,5 метрга тигез, юл кырыйларының киңлеге - 0,5 шәр метр. Аларны бар булган урман юллары челтәрләренә өстәмә коралар, янгын куркынычы булган урыннарга һәм сулыкларга автотранспорт белән үтеп керүне тәэмин итәр өчен. Аларга шулай ук табигый грунт юллары, квартал урман юллары һәм төрле трассалар кертелә |
| 2.12 | Көчләрне һәм чараларны янгын сүндерү урынына илтеп җиткерү вакыты | Янгын күренгәннән соң 3 сәгатьтән дә артмаска тиеш. Ә янгын куркынычы югары булган кишәрлекләр өчен 0,5 – 1,0 сәгатьтән дә артмаска тиеш |
| 2.13 | Янгын урынына бару юлына китә торган вакытны исәпләп чыгарганда юлларның, сукмакларның яисә җәяүлеләр узып йөрерлек урыннарның сикәлтәлеген һәм җир өсте рельефын исәпкә алу өчен аларны озынайту коэффициентлары | |
| | 1 типлы урман хуҗалыгы юллары өчен<br>3 типлы (янгынга каршы) урман хуҗалыгы юллары өчен | тигез урыннарда - 1,1;<br>калкулыклы - 1,25<br>тигез урыннарда - 1,15;<br>калкулыклы - 1,65 |
| 2.14 | Янгын сүндерүче эшченең хәрәкәт итү тизлеге | Гадәттә 1- 3 чм/сәг (автомобиль юлыннан коралларын күтәреп янгын урынына килгәндә) |
| 2.15 | Җир өстендә патруль уздыру маршрутларын планлаштыру: | |
| 2.15.1 | Урнаштыру урыннары | Агач-куаклар аз булган урыннарда (15% һәм аннан да түбән) һәм территория буйлап вак урман кишәрлекләре урнашканда. Кырсаклагыч утыртмаларны, ерганак буйларындагы һәм балкалардагы, яшел зоналы урманнардагы, урман-далалардагы утыртмаларны саклаганда. Стационар күзәтү пунктларыннан күзәтүгә һәм авиапатрульгә өстәмә рәвештә – агач материалы әзерләү урыннарында, төрле объектлар төзү урыннарында һәм трассаларда, ял зоналарында, елгалар һәм күлләр ярлары буйлап, янгын куркынычы югары булган урыннарда |
| 2.15.2 | Патруль уздыру маршруты озынлыгы | Транспорт төренә, юллар торышына һәм саклана торган кишәрлекне карап чыгу санына бәйле рәвештә |
| 2.15.3 | Янгын куркынычы булган кишәрлекләрдә урман янгынына патруль уздыру хәрәкәте тизлеге | |
| | мотоцикллар, машиналар һәм башка транспорт чаралары | гомуми файдаланудагы шоссе юллары буйлап - 30 чм/сәг артык, урман юллары буйлап -15-20 чм/сәг. Урмансыз киңлекләрдә юл хәрәкәте иминлеге кагыйдәләре нигезендә арттырылырга да мөмкин |

Урман хуҗалыгын алып баручы урман фондын биләүчеләрне урман янгыннарын сүндерү җайланмалары һәм чаралары белән тәэмин итү нормалары 2.17.1.6 таблицада күрсәтелгән.

2.17.1.6 таблица

**Урман хуҗалыгын алып баручы урман фондын биләүчеләрне урман янгыннарын сүндерү җайланмалары һәм чаралары белән тәэмин итү нормалары**

| № п/п | Җайланма, инвентарь һәм янгын сүндерү чаралары | Үлч. берәмл. | Урманчылык | Кишәрлек урманчылыгы | Урман хуҗалыгы кишәрлеге | Карап чыгу |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Югары үтеп керешле бортлы автомобильләр (ГАЗ-66, УАЗ-3301, "Урал" һ.б.) яки вездеходлар (ЛПМ - 0,1 һ.б.) | данә | 1 | - | - | - |
| 2. | Күчмә җиһазландырылган мотопомпалар (МН-13\60 һ.б.) яки кечкенә габаритлы (МЛН-3\0,3 Л-1\0,75,МЛВ-1,МЛВ-2,МЛП-0,2 һ.б.) | данә | 2-3 | 1 | - | - |
| 3. | Су куа торган җиңсәләр (Д=26, 51 мм) | пог. м. | 300 | 100 | - | - |
| 4. | Туфрак эшкәртә торган короллы тракторлар (ПКЛ-70, ПЛ-1,2 һ.б.) | данә | 1 | 1 | - | - |
| 5. | Резин сыешлыклар (РДВ - 1500 һ.б.) | данә | 2 | 1 | - | - |
| 6. | Ут кабыза торган җайланмалар (АЗ һ.б.) | данә | 3 | 2 | - | - |
| 7. | Урман ранецлы ут сүндергечләр (РЛО-М һ.б.) | данә | 10-15 | 5 | - | - |
| 8. | Бензин пычкылары ("Дружба", "Урал" һ.б.) | данә | 2-8 | 1 | - | - |
| 9. | Торфлы баганалар (ТС-1, ТС - 2 һ.б.) | данә | 2 | - | - | - |
| 10. | Кул инструментлары: | | | | | |
| | - көрәкләр | данә | 30 | 20 | 10 | 6 |
| | - китмәннәр | данә | 10 | 5 | 5 | - |
| | - тимер тырмалар | данә | 10 | 5 | 5 | 5 |
| | - балталар | данә | 10 | 5 | 4 | 3 |
| | - аркылы пычкылар | данә | - | - | 4 | 3 |
| 11. | Эчәр сулар өчен билгеләнгән 20 литрлы бидоннар яисә канистрлар | данә | 2-4 | 1-2 | 1 | 1 |
| 12. | Су өчен 10-12 литрлы тимер чиләкләр / каен сыешлыклары | данә | 10 | 5 | 3 | 3 |
| 13. | УКВ һәм КВ диапазонлы радиостанцияләр ("Кактус, "Ромашка", "Карат-М", һ. б.). Радиоэлемтә оештырылганда | данә | 2-3 | 1 | - | - |
| 14. | Су өчен кружкалар | данә | 5-10 | 5 | 5 | 4 |

| № п/п | Җайланма, инвентарь һәм янгын сүндерү чаралары | Үлч. берәмл. | Урманчылык | Кишәрлек урманчылыгы | Урман хуҗалыгы кишәрлеге | Карап чыгу |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 15. | Беренче ярдәм аптечкасы | данә | 3-4 | 1-2 | 1 | 1 |
| 16. | Индивидуаль яра бәйләү пакетлары | данә | Янгын сүндерүдә катнашучылар санына карап | | | |
| 17. | Кизү тору буенча махсус кием (куртка, итекләр, җиңсәләр), саклагыч күзлекләр, респираторлар | ком. | Үзәк предприятие, урманчылык булганда янгын сүндерү командасы әгъзалары санына карап | | | |

## 2.17.2. Урманнарны зарарлы организмнардан саклауга карата таләпләр

Урманнарны зарарлы организмнардан яклау Россия Федерациясе Урман кодексының 54-56 статьялары һәм “Үсемлекләр карантины турында” 15.07.2000 ел, №99-ФЗ Федераль закон, 29.06.2007 ел, №414 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләре (алга таба – Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләре) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарны яклау зарарлы организмнарны (үсемлекләрне, хайваннарны, билгеле бер шартларда урманнарга һәм урман ресурсларына зарар китерерлек авыру кузгатучы организмнарны) ачыклауга һәм алар таралуны булдырмауга юнәлдерелә, карантин объектларга кертелгән зарарлы организмнар чыганаклары барлыкка килгән очракта, аларны локальләштерүгә һәм бетерүгә.

Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләре урманнарны зарарлы организмнардан, шулай ук зарарлы йогынтыдан яклауның бердәм тәртибен һәм шартларын, шулай ук урманнарда санитар иминлек тәэмин итүгә юнәлдерелгән урманнарда санитар иминлек кагыйдәләрен билгели.

Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләре һәр урман районы өчен Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

Урманнарда санитар иминлекне тәэмин итү максатларында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

а) урманнарны яклау ягыннан районлаштыру (урман патологиясе яный торган зәгыйфь, уртача һәм көчле зоналарны билгеләү);

б) урман патологиясе ягыннан тикшерү һәм урман патологиясе ягыннан мониторинглау;

в) зарарлы организмнар чыганакларын локальләштерү һәм бетерү буенча авиация һәм җир өсте эшләре;

г) санитар-савыктыру чаралары (корыган һәм зарарланган урман үсентеләрен кисү, урманнарны чүптән, пычранудан һәм башка тискәре йогынтыдан яклау);

д) урманнардан файдалануга карата санитар таләпләр урнаштыру.

Арендага бирелгән урман кишәрлекләрендә санитар-савыктыру чаралары шушы кишәрлекләрнең арендаторлары тарафыннан урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарда санитар иминлек кагыйдәләре белән билгеләнгән таләпләр урманнарны үзләштерүне планлаштырганда исәпкә алына.

Урманнарда санитар иминлекне тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда алынган документлаштырылган мәгълүмат дәүләт урман реестрына кертү өчен билгеләнгән тәртиптә тапшырыла.

Урман патологиясе ягыннан тикшерү һәм урман патологиясе ягыннан мониторинг, зарарлы организмнар чыганакларын локальләштерү һәм бетерү, санитар-савыктыру чараларын билгеләү һәм уздыру эшләре Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы тарафыннан расланган методик документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.17.2.1 таблица

**Урманнарны яклау чараларының еллык күләме**

| № п/п | Чараларның исеме | Үлчәү берәмлеге | Проектланган | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Урман патологиясе ягыннан тикшерү | га | 4000 | |
| 2. | Туфрак казулар | чокырмлар | 100 | |
| 3. | Җир өстендәге юк итү чаралары | га | 580 | Зарарлану чыганаклары барлыкка килүгә карап |
| 4. | Питомникларга профилактик сиптерүләр (серкәләндерүләр) | га | 20 | Барлык чәчүлек мәйданында |
| 5. Биологик көрәш чаралары | | | | |
| 5.1 | Кош ояларын кору һәм элеп чыгу | данә/га | 100 | |
| 5.2 | Ояларны рәтләү | данә | 100 | |
| 5.3 | Парсыз ефәк күбәләгенә, яшел имән яфрак төргечләренә, дүләнә яфрак төргечләренә карата аттрактант тозаклар куллану. | га | 400 | Кирәк булганга карап |
| 5.4 | Кырмыска ояларын киртәләү | данә/га | 80 | |
| 5.5 | Кырмыска ояларын күчерү (бүлеп чыгару) | оялар | 20 | |
| 6. Оештыру-хуҗалык чаралары | | | | |
| 6.1 | Сак почмакларын оештыру | данә | 1 | Урманчылык каршында |
| 6.2 | Ашлаглар урнаштыру | данә | 20 | |
| 6.3 | Әңгәмәләр, халык белән лекцияләр үткәрү, белгечләр белән | әңгәмәләр | 12 | |
| 6.4 | Корткыч һәм авыру чыганаклары барлыкка килүне күзәтеп тору | | | |
| 6.5 | Урманны саклау буенча лаборатория җайланмаларын, күрсәтмә пособиеләрне, әдәбият сатып алу | мең сум | 20 | |
| 6.6 | Урман саклауны пропагандалау | мең сум | 3,0 | |
| 6.7 | Урманнарны чүпләрдән чистарту | га | 2014 – 450;<br>2015 – 350;<br>2016-2018 – 300 | |

Урманнардан файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

а) пестицидлар һәм агрохимикатлар яисә кешеләр сәламәтлеге һәм әйләнә-тирә мохит өчен куркыныч булган бүтән матдәләр, җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүгә карата Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләрне бозу нәтиҗәсендә туфракны пычрату;

б) урман бүлемтекләрен чистарту эшләрен, шулай ук гражданнарга яисә юридик затларга бирелгән урман кишәрлекләрен урман законнарында билгеләнгән тәртиптә шушы кишәрлекләрне максатчан файдалану өчен яраклы хәлгә китерү эшләрен яисә рекультивация эшләрен башкармау яисә вакытында башкармау;

в) авыл хуҗалыгы эшләрен алып бару өчен бирелгән урман кишәрлекләрендә авыл хуҗалыгы терлекләрен киртәләмәгән урыннарда, көтүчесез яисә бәйләмичә көтү;

г) кырмыска ояларын, кош ояларын, хайван өннәрен яисә башка яшәү урыннарын юк итү (туздыру);

д) урманнарда урнашкан мелиоратив системаларны юк итү яисә аларга зыян салу;

е) урманнарны сәнәгать һәм көнкүреш калдыклары белән пычрату;

ж) урманнарга зарар китерерлек бүтән гамәлләр.

Урманнарда табигый экологик системаларга хас булмаган, шулай ук ясалма юл белән чыгарылган һәм үрчүләрен тикшереп торуның нәтиҗәле чаралары булмаган үсемлекләр, хайваннар һәм башка организмнар үрчетү һәм алардан файдалану тыела.

Сайланма кисүләр һәм урманнарны карап тоту барышында беренче чиратта корыган һәм зарарланган агачлар киселә.

Үзагачны зарарлый торган корткыч (зыян салгыч) организмнар чыганакларында кисүләрдән калган калдыклар, урман законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланган янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәгән килеш, яндырылырга тиеш.

Диләнкеләрне эшләгәндә һәм линияле объектлар трассалары өчен корып куйганда кисүләрдән калган калдыкларны урман кырыена (урман диварына таба) этеп кую тыела.

Язгы-җәйге чорда әзерләнгән үзагачны урманнарда, кабыгын алмыйча (кабыксыз) яисә пестицидлар белән эшкәртмичә, 30 көннән дә артык саклау (калдыру) рөхсәт ителми.

Әзерләнгән агач материалын кабыгын алмыйча яисә пестицидлар белән эшкәртмичә урманнарда саклауны (калдыруны) тыя торган конкрет сроклар (даталар) урман үсентеләре зоналары һәм урман районнары буенча Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы тарафыннан билгеләнә.

Агызу өчен билгеләнгән агач материалын химик эшкәртү тыела.

Кәүсә корткычлары оялаган әзерләнгән агач материалы алар очып чыкканчы инсектицидлар белән эшкәртелергә яисә кабыгыннан арындырылырга тиеш (кабык бетерелергә тиеш). Әзерләнгән агач материалына яклау чаралары аз нәтиҗә бирә торган яисә бетерүе мөмкин булмаган кәүсә корткычлары оялаган

очракта, мондый агач материалын кичекмәстән урманнан чыгарырга яисә эшкәртергә кирәк.

Чәер әзерләү өчен зарарлы организмнар чыганакларында урнашкан, шулай ук зәгыйфьләнгән урман үсентеләре бирелми.

Чәер әзерләү өчен бүлеп бирелгән урман үсентеләрендә аны әзерли башлаганчы корып баручы һәм корыган агачлар киселә.

Чәер әзерләүне, шулай ук агач булмаган урман ресурслары (агачлар һәм куаклар кайрылары, чыбык-чабык, ботаклардан терлек азыгы, чыршы, пихта, нарат һәм (яисә) башка ылыслы токымнарның ботаклары, яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршылар һәм (яисә) башка ылыслы агачлар, мүк, урман туфрагындагы үсемлекләр җәймәсе, камыш, кыяклылар) һәм башка шундый урман ресурслары әзерләү һәм җыюны зарарлы организмнар барлыкка килүне һәм агачлар коруны булдырмый торган алымнар белән башкару рөхсәт ителә.

## № 13 хисап-технологик карта
## Туфракны алдан әзерләмичә үсентеләр утыртып, ылыслы культуралар булдыру

Урман үстерү шартларының тибы: яңа коры наратлыклар– В3-2 һәм юеш ылыслылар урманчыклары һәм катнаш урманчыклар – С2, С2-3, Д2, Д3 (куаксыман ачы җиләклекләр, катлаулы, яңа кара җиләклекләр, кара җиләкле-ачы җиләкле)

Туфраклар – көлсу, кәсле-көлсу, кәсле, соры урман туфрагы, көлсу-комлы, балчык катыш.

Киселгән урыннар - кылганлы, паллы, болынлы, кура җиләкле, озын үләнле кисекләрдән чистартылган типлар.

Түмәрләре саны 1 гектарга 900 данә

Төп токым: чыршы

1 гектарга чыгымнар

| № п/п | Эшләрнең исеме | Машиналарның маркалары | Үлч. берәм. | Чыгымнар күләме |
|---|---|---|---|---|
| 1. | 2,5 мең данә үсентеләрне вакытлыча казып кую һәм утыртуга әзерләү | | м/сәг | 44,75 |
| 2. | Үсентеләрне, рәтләр арасын 4 м ясап, механикалаштырылган утырту, рәттә 1 м саен – 2,5 км<br>4-5 еллык чыршы үсентеләре | ЛХТ-55, (ТДТ-40М СУН-3) | м/см<br>т.данә<br>ч/ч | 0,30<br>2,5<br>5,28 |
| 3. | Рәтләр янында (2 км х 10 = 20 км) туфракны йомшартып һәм үләннәрне юк итү юлы белән культураларны механикалаштырылган икенче мәртәбә (1 – 1) карау (2,5 х 2 = 5 км) | ЛХТ-55, (ТДТ-40М СУН-3) | м/см | 0,45 |
| 4. | Культураларны 1 – 2 мәртәбә кулдан карау – 1,5 м киңлектәге һәм 2500 м озынлыктагы полоса белән утырту урыннары тирәли үләннәрне һәм шытымнарны чабып чыгу (2500 х 2 = 5000 м) | | м/сәг | 45,0 |

Чыгымнар сводкасы

| Исеме | Үлч. берәмл. | Чыгымнар |
|---|---|---|
| Трактор ЛХТ - 55 | маш/см. | 0,75 |
| Урман утырту машинасы СКЛ - 1А | маш/см. | 0,30 |
| Көлтә КЛБ-1,7 | -//- | 0,45 |
| Урман утырту машинасы | -//- | |
| Дүрт-биш еллык чыршы үсентеләре | мең данә | 2,5 |
| Урманчылык эшләре | кеше/сәг | 95,03 |

## № 16 хисап-технологик карта
## Камылдан яңарту юлы белән кисүләр урыннарында мәйданчыкларга чәчкеннәр утырту юлы белән ылыслы токымнар мәйданнары булдыру

Урман үстерү шартларының тибы: яңа һәм дымлы нарат урманнары, нарат катыш урманнар һәм башка ылыслылар катыш урманнар – А2-3, В3, С2-3 (нарат җиләкле, яңа кара җиләкле, ачы җиләкле).

Туфраклар: кәсле-көлсу, комлы, ярым комлы һәм ярым балчыклы.

Төп токым: нарат, чыршы, карагай.

1 гектарга чыгымнар

| № п/п | Эшләрнең исеме | Машиналар һәм җиһазлар маркалары | Үлч. берәм. | Чыгымнар күләме | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Туфракның категориясе | |
| | | | | җиңел | уртача |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| А. Яңа наратлыклар һәм нарат катыш урманнар А2, В2 (нарат җиләкле) | | | | | |
| 1. | Көрәк штыгы тирәнлегендә, 0,5 х 0,5 м күләмендәге 2200 мәйданчыкның туфрагын кулдан йомшартып, кулдан әзерләү – 550 кв. м | | м/сәг | 46,86 | 64,90 |
| 2. | 2,2 мең данә чәчкеннәрне вакытлыча казып кую һәм утыртуга әзерләү | | м/сәг | 2,22 | 2,22 |
| 3. | 2200 чәчкенне мәйданчыкта берәм-берәм кулдан утырту<br>Ике еллык нарат чәчкеннәре | | м/сәг<br>мең данә | 14,10<br>2,20 | 19,21<br>2,20 |
| 4. | Культураларны дүрт мәртәбә (1 – 1 – 1 – 1) кулдан карау – 550 кв. м мәйданда чәчкеннәр тирәсендә үлән һәм шытымнарны чабу (550 х 4 = 2200 кв. м) | | м/сәг | 8,80 | 8,80 |
| Вариант | | | | | |
| 4а | Мәйданчыкларда туфрак йомшартып, катнаш урманнар зонасында культураларны дүрт мәртәбә (1 – 1 – 1 – 1) кулдан карау (2200 х 4 = 8800 данә) | | м/сәг | 72,16 | 102,08 |
| Б. Дымлы наратлыклар һәм нарат катыш урманнар (яңа ярдәмче типлар) А3-2, В3-2 (яңа кара җиләкле) | | | | | |
| 1. | 1 х 1 м зурлыгындагы 1500 мәйданчыкны көрәк штыгы | | м/сәг | 127,80 | 177,00 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | тирәнлегендә туфрагын йомшартып әзерләү – 1500 кв. м | | | | |
| 2. | Вакытлыча казып кую һәм утыртуга әзерләү – 3000 данә | | м/сәг | 3,03 | 3,03 |
| 3. | 3000 чәчкенне мәйданчыкта икешәрләп кулдан утырту<br>Ике еллык нарат чәчкеннәре | | м/сәг<br>мең данә | 19,23<br>3,00 | 26,19<br>3,00 |
| 4. | Чәчкеннәр тирәли үләнен һәм шытымнарын чабып һәм җиргә аударып, 1500 кв. м мәйданда культураларны дүрт мәртәбә (1 – 1 – 1 – 1) кулдан карау (1500 х 4 = 6000 кв. м) | | м/сәг | 24,0 | 24,0 |
| Вариант | | | | | |
| 4а | Мәйданчыкларда туфрак йомшартып, катнаш урманнар зонасында культураларны дүрт мәртәбә (1 – 1 – 1 – 1) кулдан карау (1500х4=6000 данә) | | м/сәг | 81,60 | 106,20 |
| В. Яңа һәм дымлы ылыслылар катыш урманнар С2-3 (ачы җиләкле, катлаулы типлар) | | | | | |
| 1. | Көрәк штыгы тирәнлегендә, 1 х 1 м күләмендәге 880 мәйданчыкның туфрагын кулдан йомшартып, кулдан әзерләү | | м/сәг | 68,16 | 94,40 |
| 2. | Вакытлыча казып кую һәм утыртуга әзерләү – 2400 данә | | м/сәг | 2,42 | 2,42 |
| 3. | 2400 чәчкенне мәйданчыкта 3 данәләп кулдан утырту | | м/сәг | 15,38 | 20,95 |
| | Ике еллык чыршы чәчкеннәре | | мең данә | 2,4 | 2,4 |
| 4. | Культураларны алты мәртәбә (1 – 2 – 2 – 1) кулдан карау – 800 кв. м мәйданда чәчкеннәр тирәсендә үлән һәм шытымнарны чабу (800 х 6 = 4800 кв. м) | | м/сәг | 19,20 | 19,20 |
| Вариант | | | | | |
| 4б | Мәйданчыкларда туфрак йомшартып, катнаш урманнар зонасында культураларны алты мәртәбә (1 – 2 – 2 – 1) кулдан карау (800 х 6 = 4800 данә) | | м/сәг | 65,28 | 84,96 |

Чыгымнар сводкасы

| Исеме | Үлч. берәмл. | Чыгымнар | |
|---|---|---|---|
| | | Туфракның категориясе | |
| | | җиңел | уртача |
| А. Яңа наратлыклар һәм нарат катыш урманнар А2, В2 (нарат җиләкле) | | | |
| Урманчылык эшләре | к/сәг | 71,98 | 95,13 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Ике еллык нарат чәчкеннәре<br>Вариант<br>Урманчылык эшләре | мең данә<br><br>к/сәг | 2,20<br><br>135,34 | 2,20<br><br>188,41 |
| Ике еллык нарат чәчкеннәре | мең данә | 2,20 | 2,20 |
| Б. Дымлы наратлыклар һәм нарат катыш урманнар (яңа ярдәмче типлар) | | | |
| Урманчылык эшләре<br>Ике еллык нарат чәчкеннәре | к/сәг<br>мең данә | 174,06<br>3,00 | 230,22<br>3,00 |
| Вариант<br>Урманчылык эшләре<br>Ике еллык нарат чәчкеннәре | <br>к/сәг<br>мең данә | <br>231,66<br>3,00 | <br>312,42<br>3,00 |
| В. Яңа һәм дымлы ылыслылар катыш урманнар С2-3 (ачы җиләкле, катлаулы типлар) | | | |
| Урманчылык эшләре<br>Ике еллык нарат чәчкеннәре<br>Вариант<br>Урманчылык эшләре<br>Ике еллык нарат чәчкеннәре | к/сәг<br>мең данә<br><br>к/сәг<br>мең данә | 105,16<br>2,40<br><br>151,24<br>2,40 | 136,97<br>2,40<br><br>202,73<br>2,40 |

## № 17 хисап-технологик карта
## Камылдан яңарту юлы белән кисүләр урыннарында мәйданчыкларга чәчкеннәр утырту һәм имән чикләвекләре чәчү юлы белән культуралар булдыру

Урман үстерү шартларының тибы: яңа һәм дымлы наратлыклар, нарат катыш урманнар һәм ылыслылар катыш урманнар – А2-3, В2-3, коры, яңа, дымлы ылыслылар катыш урманнар һәм бер генә токым ылыслылар урманнары – С1-2, С3, Д1, Д2, Д3.

Туфраклар: кәсле- кәсле-көлсу, комлы, ком катыш һәм ярым балчыклы, соры урман һәм кәсле-комлы һәм ярым балчыклы, селтеле кара туфраклар һәм көлле ком катыш һәм ярым балчыклы, болын-кара туфраклы ком катыш ярым балчыклы һәм ярым балчык катыш комлы, черемәле-карбонатлы ярым балчыклы.

Төп токымнар: нарат, чыршы, карагай, имән (киң яфраклы урманнар зонасында).

Нарат культуралары наратлыкларда, нарат катыш урманнарда һәм ылыслылар катыш урманнарда проектлана, чыршы һәм карагай – ылыслылар катыш урманнарда, имән – бер токым ылыслы урманнарда.

1 гектарга хисап

| Эшләрнең исеме | Үлч. берәмл. | Чыгымнар күләме | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Туфракның категориясе | | |
| | | җиңел | уртача | авыр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| А. Яңа наратлыклар һәм нарат катыш урманнар А2, А3, В2, В3 | | | | |
| 1. Көрәк штыгы тирәнлегендә, 1 х 1 м күләмендәге 1400 мәйданчыкның туфрагын кулдан йомшартып, кулдан әзерләү – 1400 кв. м | к/сәг | 119,28 | 165,20 | - |
| 2. 2860 мең данә чәчкеннәрне вакытлыча казып кую һәм утыртуга әзерләү | м/сәг | 2,83 | 2,83 | - |
| 3. 2800 чәчкенне мәйданчыкта 2 данәләп кулдан утырту | м/сәг | 17,95 | 24,44 | - |
| 4. Үләннәрне юк итеп, мәйданчыкларда туфракны алты мәртәбә (2- 2- 2) кулдан йомшарту (1400 х 6 = 8400 данә) | к/сәг | 114,24 | 148,68 | - |
| Ике еллык нарат чәчкеннәре | мең данә | 2,8 | 2,8 | - |
| Б. Коры, яңа һәм дымлы ылыслылар катыш урманнар һәм бер генә токым ылыслылар урманнары – С1,С2,С3,Д1,Д2,Д3 | | | | |
| 1. Көрәк штыгы тирәнлегендә, 1 х 1 м күләмендәге 1000 мәйданчыкның туфрагын кулдан йомшартып, кулдан әзерләү– 1000 кв. м | к/сәг | 85,20 | 118,0 | 178,0 |
| 2. 3000 мең данә чәчкеннәрне вакытлыча казып кую һәм утыртуга әзерләү | м/сәг | 3,03 | 3,03 | 3,03 |
| 3. 3000 чәчкенне мәйданчыкта 3 данәләп кулдан утырту | м/сәг | 19,23 | 26,19 | 26,19 |

| Эшләрнең исеме | Үлч. берәмл. | Чыгымнар күләме | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Туфракның категориясе | | |
| | | җиңел | уртача | авыр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Ике еллык чыршы чәчкеннәре | мең данә | 3,00 | 3,00 | 3,00 |
| Вариант | | | | |
| 3а 1000 мәйданчыкта (3әр чокыр) чокырларга 3әр данә имән чикләвеге утырткан өчен – 3000 утырту урыны<br>Имән чикләвекләре | м/сәг<br>кг<br>мең данә | -<br>- | 15,15<br>27 | 18,00<br>27 |
| Үләннәрне юк итеп, мәйданчыкларда туфракны 4-8 мәртәбә (2- 2- 2-2) кулдан йомшарту (1000 х 8 = 8000 данә) | м/сәг | 108,80 | 141,60 | 196,80 |
| Чыгымнар сводкасы | | | | |
| А. Яңа наратлыклар һәм нарат катыш урманнар – А2, А3, В2, В3 | | | | |
| Урманчылык эшләре<br>Ике еллык нарат чәчкеннәре | м/сәг<br>мең данә | 254,30<br>2,8 | 341,15<br>2,8 | - |
| Б. Коры, яңа һәм дымлы ылыслылар катыш урманнар һәм бер генә токым ылыслылар урманнары – С1, С2, С3, Д1, Д2, Д3 | | | | |
| Урманчылык эшләре<br>Ике еллык чыршы чәчкеннәре | м/сәг<br>мең данә | 216,26<br>3,00 | 288,82<br>3,00 | 404,02<br>3,00 |
| Вариант<br>Урманчылык эшләре<br>Имән чикләвекләре | м/сәг<br>кг | -<br>- | 274,75<br>27,0 | 392,80<br>27,0 |

2.17.3.8 таблица

**Урман типларының төрле төркемнәрендәге урмансыз җирләрне торгызу буенча өстенлекле ысуллар**

| Төп өстенлек итүче токым | Урман типлары төркеме | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | С бел. | С бр. | С чер | С пр. | С сф.д. | С тр.лп | С к.ч. | С слж. | С т.ос | Е бр. | Е ө. | Е пр. | Е сф.д. | Е слж. | Е к. | Д слж. | Д пм. | Б ос | Б т.ос. | Зир. | Тал |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 |
| 1. Ярдәм итмичә табигый торгызылу | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| С, Л | - | | | + | + | | | - | | | | | | | | | | | | | |
| Е, П | | | | | | | | | | - | - | + | + | | | | | | | | |
| Д, Я, Кл Элмә | | | | | | | | | | | | | | | | - | + | | | | |
| Б | | - | - | + | | - | - | - | | - | - | + | | - | - | - | + | + | - | | |
| Ос, Т | | | + | + | | - | - | - | | | - | + | | - | - | - | + | | | | |
| Лп | | | | | | - | | - | | | | | | - | - | - | + | | | | |
| К. зирек. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | + | |
| Тал др. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | + |
| 2. Табигый торгызылуга туфракны минеральләштереп ярдәм итү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| С, Л | - | + | + | - | - | + | + | - | - | | | | | | | | | | | | |
| Е, П | | | | | | | | | - | + | - | - | + | - | | | | | | | |
| Д, Я, Кл Элмә | | | | | | | | | | | | | | | - | - | | | | | |
| Б | | - | + | - | | + | + | - | - | + | - | - | - | | - | - | | | | | |
| Ос, Т | | | + | - | | + | + | - | - | + | - | - | - | | - | - | | | | | |
| Лп | | | | | | - | - | - | | | | | | - | - | - | | | | | |
| К. зирек. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | - | |
| Тал др. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| Төп өстенлек итүче токым | Урман типлары төркеме | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | С бел. | С бр. | С чер | С пр. | С сф.д. | С тр.лп | С к.ч. | С слж. | С т.ос | Е бр. | Е ө. | Е пр. | Е сф.д. | Е слж. | Е к. | Д слж. | Д пм. | Б ос | Б т.ос. | Зир. | Тал |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 |
| 3. Шытымны саклау | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| С, Л | - | + | + | - | - | + | + | - | - | | | | | | | | | | | | |
| Е, П | | | | | | | | | - | + | - | - | + | - | | | | | | | |
| Д, Я, Кл Элмә | | | | | | | | | | | | | | | - | - | | | | | |
| Б | | - | + | - | | + | + | - | - | + | - | - | - | | - | - | | | | | |
| Ос, Т | | | + | - | | + | + | - | - | + | - | - | - | | - | - | | | | | |
| Лп | | | | | | - | - | - | | | | | | - | - | - | | | | | |
| К. зирек. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | - | |
| Тал др. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4. Урман культуралары | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| С, Л | + | + | + | - | - | + | + | + | + | | | | | | | | | | | | |
| Е, П | | | | | | | | | | + | + | - | - | + | + | | | | | | |
| Д, Я, Кл Элмә | | | | | | | | | | | | | | | | + | - | | | | |
| Б | | + | + | - | - | + | + | + | + | + | + | | | + | + | + | | | | | |
| Ос, Т | | | + | - | - | + | + | + | + | + | + | | | + | + | + | | | | | |
| Лп | | | | | | | | + | | + | | | | | | + | | | | | |
| К. зирек. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | - | |
| Тал др. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | - |

Искәрмәләр: +- киңәш ителүче чара;
- - киңәш ителми торган чара;

буш графа - әлеге токым бу урманнар типларының төркемнәренә хас түгел.

## 2.18. Урман үсү зоналары һәм урманлы районнар буенча урманнардан файдалануга карата таләпләрнең үзенчәлекләре

"Россия Федерациясендә урман үсү зоналары һәм урманлы районнар исемлеген раслау турында" 09.03.2011 ел, №61 Рослесхоз боерыгы нигезендә Урманчылыкның барча территориясе Россия Федерациясенең Европа өлешендәге урман-дала районында урнашкан.

Бүлектә китерелгән нормативлар Россия Федерациясенең Европа өлешендәге урман-дала зонасының урман-дала районына туры килә.

# 3 БҮЛЕК. УРМАННАРНЫ ФАЙДАЛАНУДАГЫ ЧИКЛӘҮЛӘР

## 3.1. Урманнарның максатчан билгеләнеше төрләре буенча чикләүләр

Урманнарны максатчан билгеләнеше төрләре һәм яклanучы урман категорияләре буенча чикләүләр 3.1 нче таблицада китерелә.

3.1 таблица

**Урманнарның максатчан билгеләнеше төрләре буенча чикләүләр**

| № п/п | Урманнарның максатчан билгеләнеше | Урманнарны файдалану буенча чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Су саклау зоналарында урнашкан урманнар | Тыела:<br>1) урман утыртмаларын тоташ кисү;<br>2) урманнарны саклау һәм яклау өчен, шул исәптән фәнни максатларда агулы химия препаратларын куллану;<br>3) авыл хуҗалыгын алып бару, умартачылык һәм печән чабудан гайре;<br>4) урман плантацияләрен булдыру һәм эксплуатацияләү, урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру;<br>5) линияле объектлардан һәм гидротехника корылмаларыннан гайре, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру. |
| 2. | Табигый һәм башка төр объектларны саклау функциясен үтәүче урманнар: | Урман утыртмаларын тоташ кисү тыела. |
| | Россия Федерациясе субъектлары милкендә булган, гомуми кулланылыштагы тимер юл, гомуми кулланылыштагы федераль автомобиль юллары, гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары буйларындагы саклык урманнары полосалары | Тыела:<br>1) техник регламент белән каралган киңлектән киңрәк итеп линия корылмаларны кисү;<br>2) урманда аяк асты җәймәсен һәм мүк җыю и әзерләү. |
| | а) урман-парк зоналары | Тыела:<br>1) урманнарны саклау һәм яклау өчен, шул исәптән фәнни максатларда агулы химия препаратларын куллану;<br>2) эшчәнлек төрләрен аучылык хуҗалыгы |

| № п/п | Урманнарның максатчан билгеләнеше | Урманнарны файдалану буенча чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | өлкәсендә башкару;<br>3) авыл хуҗалыгын алып бару;<br>4) файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару;<br>5) гидротехника корылмаларыннан гайре, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру.<br>6) урман плантацияләрен булдыру һәм эксплуатацияләү, урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру. |
| | б) яшел зоналар | Тыела:<br>1) урманнарны саклау һәм яклау өчен, шул исәптән фәнни максатларда агулы химия препаратларын куллану;<br>2) эшчәнлек төрләрен аучылык хуҗалыгы өлкәсендә башкару;<br>3) авыл хуҗалыгы алып бару, печән чабу һәм умартачылыктан гайре, шулай ук авыл хуҗалыгы алып бару, печән чабу һәм умартачылык максатларында койма кою;<br>4) файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару;<br>5) капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, гидротехника корылмаларыннан, элемтә линияләреннән, электрүткәргеч линияләрдән, җир асты торбаүткәргечләреннән гайре;<br>6) урман плантацияләрен булдыру һәм эксплуатацияләү, урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру. |
| 3. | Кыйммәтле урманнар | Урман үсентеләрен тоташ кисүләр, әгәр сайлап алып кисүләр яклаучы урманнарның максатчан билгеләнешен саклап калуны тәэмин итә торган үз функцияләрен югалта барган урман үсентеләрен алмаштыруны тәэмин итми торган очраклардан гайре.<br>Тыела:<br>1) линияле объектлардан һәм гидротехника корылмаларыннан гайре, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру;<br>2) урман плантацияләрен булдыру һәм эксплуатацияләү, урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру. |
| 4. | Эксплуатация урманнары | Урманнарны файдалануның барлык төрләре рөхсәт ителә. |

## 3.2. Махсус сакланучы урман кишәрлекләре буенча төрләрне чикләү

Махсус сакланучы урман кишәрлекләренә карата хокукый режим Россия Федерациясе Урман кодексының 102, 107 статьялары, Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгының "Су саклау зоналарында урнашкан урманнарны, табигый һәм башка объектларны яклау функциясен үтәүче урманнарны, кыйммәтле урманнарны, һәм шулай ук махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнарны файдалану, саклау, яклау, яңадан үстерү үзенчәлекләрен раслау турында" 14.12.2010 ел, №485 (алга таба - Үзенчәлекләр) боерыгы белән регламентлана.

Махсус сакланучы урман кишәрлекләрендә максатчыл билгеләнеше һәм файдалы функцияләре ярашмаган эшчәнлек башкару тыела.

Махсус сакланучы урман кишәрлекләре төрләре буенча чикләү 3.2 таблицада күрсәтелгән.

3.2 таблица

**Махсус сакланучы урман кишәрлекләре төрләре буенча чикләүләр**

| № п/п | Махсус сакланучы кишәрлек төрләре (МСК) | Урманнарны файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Су объектлары, чокыр сөзәклекләрендә урнашкан ярсаклагыч, туфраксаклагыч урман кишәрлекләре.<br>Киңлекләре түбәндәгечә булган ярсаклагыч полосаларның чикләрендәге урман кишәрлекләре:<br>кире яки нульле авышлыкка ия булган су яры өчен - 30 м;<br>өч градуска кадәр авышлыкка ия булган су яры өчен - 40 м;<br>өч һәм аннан да югарырак градуска кадәр авышлыкка ия булган су яры өчен - 50 м;<br>агар сазлыклар һәм агынты күлләрнең һәм тиешле су агымнары чикләрендә урнашканнар өчен - 50 м;<br>Чокыр сөзәклегендә урнашкан, чокыр кырыена тоташучы урманнар һәм 50 метрга кадәрге киңлектәге урман полосалары. | Тыела:<br>- Россия Федерациясе Урман кодексының 17 статьясының 4 өлешендә, 21 статьясының 5,1 өлешендә каралган очраклардан гайре, тоташ кисүләрне үткәрергә;<br>- урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру;<br>- урман плантацияләрен булдыру;<br>- авыл хуҗалыгын алып бару, умартачылык һәм печән чабудан гайре;<br>- линияле объектлардан һәм гидротехника корылмаларыннан гайре, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру;<br>- әлеге урман районында табигый шартларда үсеп китә алмаган агачлар, куаклар, лаианалар, башка урман үсемлекләре төрләренең (токымнарының) интродукциясе.<br>Сайланма кисүләрне бары тик һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларына карата гына |
| 2. | Урмансыз киңлекләр белән чиктәш | |

| № п/п | Махсус саклanучы кишәрлек төрләре (МСК) | Урманнарны файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | урман авызлары. Урмансыз киңлекләр чикләреннән 100 м киңлектә урнашкан, урман кырыеннан кимендә 1,5-2,0 км ераклыктагы урман авызлары. | башкарырга ярый. Даими урманорлык кишәрлекләрендә агач токымнарының җимеш җирүен карап тоту тәртибендә сайланма кисүләрне башкару рөхсәт ителә. |
| 3. | Даими урманорлык кишәрлекләре Табигый югары сыйфатлы урманнарның һәм урман культураларының озак вакытлы чор дәвамында кыйммәтле чәчүлекле сыйфатлары булган агач токымнары орлыкларын алу һәм даими әзерләү өчен формалаштырылган югары җитештерүчәнлекле кишәрлекләре. | |
| 4. | Халыкара Кызыл китапка, РФ Кызыл китабына һәм РФ субъектларының Кызыл китапларына кертелгән реликтив һәм эндемик үсемлекләре булган урман кишәрлекләре. | |
| 5. | Сирәк һәм югалу куркынычы янаган кыргый җәнлекләрнең яшәү урыннары.<br>Халыкара Кызыл китапка, РФ Кызыл китабына һәм РФ субъектларының Кызыл китапларына кертелгән сирәк һәм югалу куркынычы янаган кыргый җәнлекләрнең яшәү урыннары булган урман кишәрлекләре. | |
| 6. | Тыюлыклы урман кишәрлекләре. Озак вакытлы чор дәвамында табигый формалашкан, хуҗалык эшчәнлеге һәм рекреация белән аз җимерелгән 100-150 гектар мәйданлы, дәүләт табигый тыюлыгы һәм милли паркларның тыюлык зоналары чикләренә кермәүче урман кишәрлекләре. | Тыюлыклы урман кишәрлекләрендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>1) урман утыртмаларын кисү;<br>2) урманнарны саклау һәм яклау өчен, шул исәптән фәнни максатларда агулы химия препаратларын куллану;<br>3) авыл хуҗалыгын алып бару;<br>4) файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару;<br>5) капиталь төзелеш объектларын урнаштыру.<br>6) урман эшкәртү инфраструктурасын |

| № п/п | Махсус саклanучы кишәрлек төрләре (МСК) | Урманнарны файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | булдыру;<br>7) урман плантацияләрен булдыру. |
| 7. | Башка махсус саклanучы урман кишәрлекләре: | Тыела:<br>- Россия Федерациясе Урман кодексының 17 статьясының 4 өлешендә, 21 статьясының 5,1 өлешендә каралган очраклардан гайре, тоташ кисүләрне үткәрергә;<br>- урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру;<br>- урман плантацияләрен булдыру;<br>- авыл хуҗалыгын алып бару, умартачылык һәм печән чабудан гайре;<br>- линияле объектлардан һәм гидротехника корылмаларыннан гайре, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру;<br>- әлеге урман районында табигый шартларда үсеп китә алмаган агачлар, куаклар, лаианалар, башка урман үсемлекләре төрләренең (токымнарының) интродукциясе.<br>Сайланма кисүләрне бары тик һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларына карата гына башкарырга ярый. Даими урманорлык кишәрлекләрендә агач токымнарының җимеш җирүен карап тоту тәртибендә сайланма кисүләрне башкару рөхсәт ителә. |
| | Тау районнарында урмансыз киңлекләр белән чиктәш җирдә анның өске чиге буйлап 200 м киңлектәге урман киңлекләре. | |
| | Урмансыз киңлекләрләр арасында урнашкан 100 га урман кишәрлекләре. | |
| | Тау районнарында 100-200 м киңлектәге полосалар, җирле шартларга бәйле рәвештә, 2,5 мең га артык мәйданда су җыю чикләре буенча дулкыннар һәм субүләрләр буенда урнашкан, 20°тан артык дулкыннар һәм субүләрләр барлыкка китерә торган. | |
| | Сөзәклек экспозициясенә бәйсез рәвештә 30° текә урыннар авышлыкларындагы урман кишәрлекләре. | |
| | Дәүләт табигать заказниклары һәм башка махсус сакланылучы табигать территорияләре чикләрендәге, мәйданнары аларны барлыкка китергәндә билгеләнә торган урман кишәрлекләре (АСТТ аерым урман кишәрлекләрендә файдалану режимы башка территориягә караганда катгый урнаштырылганда). | |
| | Мәйданнары аларны барлыкка китергәндә билгеләнә торган, әмма федераль әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләре чикләре буйлап кимендә 1000 м киңлектәге полосалы саклау зоналары чикләрендәге урман кишәрлекләре. | |

| № п/п | Махсус саклanучы кишәрлек төрләре (МСК) | Урманнарны файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | Көртлекләрнең гөлдерәү урыннары тирәли 300 м радиустагы урман кишәрлекләре, 10 мең га урманга 3 тән артык шундый урман кишәрлеге исәбеннән. | |
| | Елганың яисә кондызлар яши торган бүтән су объектының һәр яры буйлап 100 м киңлектәге урман полосалары. | |
| | Бал бирә торган кишәрлекләр (өлгереп килүче, өлгергән һәм картайган урман үсентеләре, даими умартачылыклар тирәли 3 км радиуста юкә һәм ак сәрби өстенлек итә торган урманнар). | |
| | Агачларны даими рәвештә җентекләп үлчәү һәм озак чорда агач-куак үсентеләре белән капланган урында урман корылышы яисә урман хуҗалыгы тамгалары белән төзекләндерелгән һәм урман корылышы планшетларына кертелгән үсентеләрне төгәл чагылдыру өчен билгеләнгән даими сынау мәйданнары. | |
| | Шифаханәләр, балалар лагерьлары, ял йортлары, пансионатлар, туристик базалар һәм башка дәвалау һәм савыктыру учреждениеләре тирәли 1 километрдан артык булмаган радиуста (дәвалау-савыктыру урыннарын шифаханә (тау шифаханәсе) саклау округларының беренче, икенче һәм өченче зоналарында яисә урман хуҗалыгын алып баруның һәм урманнардан файдалануның шундый ук режимы булган яклаучы урманнарның бүтән категорияләре урманнарында урнашмаган булсалар, алар бүленәләр. | |

| № п/п | Махсус саклануучы кишәрлек төрләре (МСК) | Урманнарны файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | 100 до 250 м киңлектәге урман полосалары, җирле шартларга карап, федераль яисә региональ туристик маршрутның ике ягына таба да. | |
| | Авыл торак пунктлары һәм бакчачылык ширкәтләре тирәли 1 км киңлектәге урман кишәрлекләре. | |

Искәрмә. Махсус яклаучы урман кишәрлекләре урнашкан җир һәм аларның мәйданы урманнар коруны проектлаганда күрсәтелә.

### 3.3. Урманнарны файдалану төрләре буенча чикләүләр

Урманнарны файдалану төрләре буенча чикләүләр 3.3 таблицада күрсәтелгән.

3.3 таблица

**Урманнарны файдалану төрләре буенча чикләүләр**

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнарны файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Үзагач әзерләү | Диләнке хисабын узып китүче (үзагач алу өчен мөмкин булган күләм) күләмдәге, һәм шулай ук кисентеләрнең яшен бозып үзагач әзерләү тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 29 статьясындагы 4 өлеше). 01.08.2011 ел, № 337 Рослесхоз боерыгы белән расланган Үзагач әзерләү кагыйдәләре нигезендә:<br>а) елга һәм чишмә үзәннәрен сөйрәмә җир трассалары һәм урман юллары сыйфатында куллану рөхсәт ителми;<br>б) диләнке чикләрендә урман утыртмаларын, үсемчелек катлавын һәм туфракларны зарарлау, урманнарны сәнәгать һәм башка калдыклар белән чүпләү рөхсәт ителми;<br>в) юлларны, күперләрне һәм агач кисеп салынган юлларны, һәм шулай ук киптерүче челтәрне, юл, гидромелиоратив һәм башка корылмаларны, су агымнарын, чишмәләрне, елгаларны саклау мөһим; |

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнарны файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | г) өемнәрне (кисеп ташланган һәм диләнкедә калдырылган агачларны исәпкә алып) һәм кисеп ташланган асылынып төшкән агачларны калдыру, саклап калынырга тиешле яшь агачны зарарлау яисә бетерү тыела.<br>д) чик, квартал, диләнке һәм башка баганаларны һәм агачлардагы һәм агач төпләрендәге билгеләрне, ярлыкларны һәм номерларны бетерү яисә зарарлау тыела;<br>е) кисүгә тиешле булмаган һәм Россия Федерациясенең Үзагач әзерләү кагыйдәләре һәм урман законнары нигезендә сакланырга тиешле агачларны, шул исәптән орлык бирүче һәм плюс агачларын кисү һәм зарарлау тыела;<br>ж) рөхсәт ителгән вакыты (рөхсәт ителгән кичектереп торуларны исәпкә алып) тәмамланганнан соң үзагач әзерләү, һәм шулай ук файдалану хокукы туктатылганнан соң яисә тәмамланганнан соң үзагач әзерләү рөхсәт ителми;<br>з) билгеләнгән вакытка (рөхсәт ителгән кичектереп торуларны исәпкә алып) үзагачны алып чыкмыйча диләнкедә калдыру рөхсәт ителми;<br>и) диләнке эшләп чыгаруның технологик картасында каралмаган урыннарга үзагач чыгару, тарттыру рөхсәт ителми;<br>к) диләнке чистарту буенча эшләрне үтәмәү яисә үз вакытында үтәмәү рөхсәт ителми;<br>л) сөйрәмә җирләрдән һәм төяү мәйданнарыннан кала туфракның өске уңдырышлы катламын юк итү рөхсәт ителми.<br>Диләнкеләрдә үзагач әзерләгәндә яшәргә яраклы, аларның табигый ареалы чикләрендә үсеп китүче (әгәр дә тиешле агач токымының урманнар составындагы мәйданы өлеше урманчылык мәйданының 1 процентыннан артып китмәсә) кыйммәтле агач токымнарын (имән, бук, корычагач, эрбет, юкә, күг, элмә, кара зирек, чәчә торган каштан) кисү рөхсәт ителми.<br>Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән зат |

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнарны файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | төрләре сакланырга тиешле.<br>Үзагач әзерләгәндә урман утыртмалары агачлары составында өч һәм аннан да күбрәк берәмлектә эрбет булган өлгергән, картайган урман утыртмаларын кисү рөхсәт ителми. |
| 2. | Чәер әзерләү | Түбәндәгеләргә кирт салу тыела:<br>а) аларны бетергәнчегә хәтле зарарлы организмнар чыганакларындагы урман утыртмаларына;<br>б) урман янгыннары, зарарлы организмнар һәм башка тискәре факторлар нәтиҗәсендә зарарланган һәм зәгыйфьләнгән урман утыртмаларына;<br>в) Россия Федерациясе законнары нигезендә үзагач әзерләү максатында өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын тоташ яки сайланма кисүләр рөхсәт ителмәгән урманнардагы урман утыртмаларына;<br>г) даими урман-орлыкчылык кишәрлекләрендә, урман-орлыклык плантацияләрендә, генетик резервацияләрдә урнашкан урман утыртмаларына, һәм шулай ук плюс агачларына, орлыклыкларга, орлык чәчәклекләренә һәм полосаларына (24.01.2012 елдан № 23 Рослесхоз боерыгы белән расланган Чәер әзерләү кагыйдәләренең 7 пункты). |
| 3. | Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу | Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу өчен үсемлекләрнең түбәндәге төрләрен куллану тыела:<br>- РФ Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгәннәрне;<br>- наркотик чара дип табылганнарны;<br>- аларның үзагачын әзерләү рөхсәт ителмәгән агачларның һәм куакларның төрләре (токымнары) исемлегенә кертелгәннәрне.<br>Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу чикләнергә яки радиоактив матдәләр белән пычранган районнарда билгеләнгән тәртиптә тыелырга мөмкин. 05.12.2011 ел, № 512 Рослесхоз боерыгы белән расланган Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу кагыйдәләре нигезендә: |

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнарны файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | - эрозиягә каршы урманнарда; су объектлары, чокыр авышлыклары буйларында урнашкан ярсаклагыч һәм туфраксаклагыч урман кишәрлекләрендә, һәм шулай ук тулылыгы 0,8-1,0 булган яшь агачларда һәм йомылмаган урман культураларында түмәр сагызын әзерләү рөхсәт ителми (13 пункт);<br>- агачларны туз әзерләү өчен кисү тыела (14 пункт);<br>- урманнардагы табигый һәм башка объектларны саклау функциясен башкаручы катламнарны җыеп алу тыела (20 пункт). |
| 4. | Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу | Аларның төрләре Кызыл китапка, Татарстан Республикасы кызыл китабына кертелгән яки наркотик матдәләр булып саналган гөмбәләрне һәм кыргый үсүче үсемлекләрне әзерләү һәм җыеп алу рөхсәт ителми.<br>Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу радиоактив матдәләр белән пычранган районнарда билгеләнгән тәртиптә чикләнергә мөмкин.<br>05.12.2011 ел, № 511 Рослесхоз боерыгы белән расланган Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу кагыйдәләре нигезендә:<br>- җимеш бирә торган агачларны кисү һәм җимешләрне әзерләү өчен ботакларны кискәләү тыела;<br>- чикләвекләрне әзерләгәндә агачларны һәм куакларны кисү, һәм шулай ук агачларны һәм куакларны зарарлый торган ысулларны куллану тыела (15 пункт);<br>- гөмбәләрне әзерләү аларның ресурсларын саклауны тәэмин итүче ысуллар белән башкарылырга тиеш (16 пункт);<br>- каен согын әзерләү өлгергән урман кишәрлекләрендә кисәренә 5 елдан да ким булмаган вакыт кала рөхсәт ителә (17 пункт);<br>- башка азык-төлек ресурсларын әзерләү аларның куаклыклары торышын начарлатмый торган ысуллар белән башкарылырга тиеш;<br>үсемлекләрне тамырлары белән өзеп алырга, |

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнарны файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | яфракларын (вайдаларын) һәм тамырларын зарарларга тыела (18 пункт). |
| 5. | Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен башкару | Яшел зоналарда һәм урман-парк зоналарында, һәм шулай ук шәһәр урманнары территорияләрендә аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлек төрләрен башкару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 105 статьясының 3 өлешендәге 2 пункт). |
| 6. | Авыл хуҗалыгын алып бару. | Су саклау зоналарында урнашкан урманнарда, речән чабу һәм умартачылыктан гайре, авыл хуҗалыгын алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 104 статьясының 1 өлешендәге 3 пункт).<br>Сак урманнырының яр буе чикләрендә җирләрне сөрү, авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү һәм алар өчен җәйге лагерьлар, ванналар оештыру тыела (Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясындагы 17 өлешнең 1, 3 пунктлары).<br>Урман-парк зоналарында авыл хуҗалыгын алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 105 статьясының 3 өлешендәге 3 пункт).<br>Яшел зоналарда, печән чабу һәм умартачылыктан, һәм шулай ук печән чабу һәм умартачылык максатларында киртәләп алулардан гайре, авыл хуҗалыгын алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 105 статьясының 5 өлешендәге 2 пункт).<br>Шәһәр урманнарында авыл хуҗалыгын алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 105 статьясының 5.1 өлеше).<br>Тыюлыклы урман кишәрлекләрендә авыл хуҗалыгын алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 107 статьясының 2 өлеше).<br>Махсус сакланучы урман кишәрлекләрендә, тыюлыклы урман кишәрлекләреннән гайре, печән чабу һәм умартачылыктан кала, авыл хуҗалыгын алып бару тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 107 статьясының 2.1 өлеше). |
| 7. | Фәнни-тикшеренү | Урманнарны фәнни-тикшеренү һәм мәгариф |

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнарны файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген башкару. | эшчәнлеге өчен файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) бирелгән урман кишәрлегеннән читтә урман үсентеләрен, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;<br>б) бирелгән урман кишәрлеген һәм аның чикләрендәге территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;<br>в) бирелгән урман кишәрлеге һәм аның чикләрендәге мәйданнарны химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату (23.12.2011 ел, № 548 Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнарны фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеге өчен файдалану кагыйдәләренең 9 пункты).<br>Агулы химик препаратларны куллану тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 103 статьясындагы 5 өлеше, 104 статьясындагы 1 өлеше, 105 статьясындагы 3 өлешенең 1 пункты). |
| 8. | Рекреация эшчәнлеген башкару | Рекреация эшчәнлеген башкаруга бирелгән урман кишәрлекләрендә табигый ландшафтлар, хайваннар дөньясы объектлары, су объектлары сакланырга тиешле (Россия Федерациясе Урман кодексының 41 статьясындагы 3 өлеше).<br>21.02.2012 ел, № 62 Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнарны рекреация эшчәнлеген башкару өчен файдалану кагыйдәләре нигезендә:<br>- рекреация эшчәнлеген башкару буенча урманнар әйләнә-тирә мохиткә һәм кеше сәламәтлегенә зарар китерми торган ысуллар белән файдаланыла (6 пункт);<br>- вакытлыча корылмаларны, физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм спорт-техник корылмаларны вакытлыча урнаштыру барыннан да элек агачлар һәм куаклар булмаган урыннарда, ә алар булмаганда - артык кыйммәтле булмаган урман утыртмалары булган урыннарда, урманнарны үзләштерү проектында билгеләнгән урыннарда рөхсәт ителә (8 пункт); |
| 9. | Урман плантацияләрен булдыру һәм аларны | Плантация булдыру максатларында түбәндәгеләрне файдалану рөхсәт ителми: |

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнарны файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | эксплуатацияләү | а) су саклау зоналарында урнашкан урманнарны;<br>б) табигый һәм башка төр объектларны саклау функциясен үтәүче урманнарны;<br>в) кыйммәтле урманнарны;<br>г) махсус саклanучы урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнарны (14.12.2010 елдан № 485 Рослесхоз боерыгы белән расланган Су саклау зоналарында урнашкан урманнарны, табигый һәм башка объектларны яклау функциясен үтәүче урманнарны, кыйммәтле урманнарны, һәм шулай ук махсус яклана торган урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнарны файдалану, саклау, яклау, яңадан үстерү үзенчәлекләренең 30 пункты). |
| 10. | Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үсемлекләрен үстерү. | 05.12.2011 ел, № 510 Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнарны җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен өчен файдалану кагыйдәләре нигезендә:<br>- җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен, беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урмансыз җирләре, һәм шулай ук урман булмаган диләнкеләрне, аланнарны һәм аларга урман культураларын утыртканчы урманның табигый торгызылуы мөмкин булмаган башка урман үсемлекләре белән капланмаган җирләр; рекультивацияләнергә тиешле (эшләнелгән торфлыклар һәм б.) (11 пункт) җирләр файдаланыла.<br>- җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен реконструкцияләүгә билгеләнмәгән азкыйммәтле утыртма кишәрлекләре файдаланырга мөмкин (12 пункт);<br>- Россия Федерациясенең Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләрен җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен куллану Россия Федерациясе Урман кодексының 59 статьясы (13 пункт) нигезендә тыела. |
| 11. | Урман үсемлекләренең утырту материалларын | 19.07.2011 ел, № 308 Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнарны урман үсемлекләренең |

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнарны файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | (үсентеләрне, чәчкечләрне) үстерү | утырту материалларын үстерү өчен файдалану кагыйдәләре нигезендә:<br>- урман үсемлекләренең утырту материалларын (үрентеләр, чәчкечләр) үстерү өчен, иң беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урман белән капланмаган җирләрне, һәм шулай ук урмансыз диләнкеләрне, аланнарны һәм башка, урман үсемлекләре белән капланмаган, урманнар урнашкан бүтән категория җирләре файдаланыла (11 пункт);<br>- урман үсемлекләренең утырту материалларын (үрентеләр, чәчкечләр) үстерү өчен урман үсемлекләренең яхшыртылган һәм сортлы орлыклары, яки, әгәр андый орлыклар булмаса, урман үсемлекләренең нормаль орлыклары кулланыла (12 пункт);<br>- урман үсемлекләренең утырту материалларын (үрентеләр, чәчкечләр) үстерү өчен урман үсемлекләренең районнарга бүленмәгән орлыкларын, һәм шулай ук сыйфаты тикшерелмәгән урман үсемлекләре орлыкларын, чәчүлекләрен һәм башкаларын куллану тыела (13 пункт);<br>- Россия Федерациясенең Кызыл китабына, Россия Федерациясе субъектларының кызыл китапларына  кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләрен урман утыртмаларының утырту материалларын (үсентеләрне, чәчкеннәрне) үстерү өчен файдалану  Россия Федерациясе Урман кодексының 59 статьясы (14 пункт) нигезендә тыела. |
| 12. | Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару буенча эшләрне башкару | Яшел зоналарда һәм урман-парк зоналарында, һәм шулай ук шәһәр урманнары территорияләрендә файдалы казылма чыганакларын эшләү тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 105 статьясының 3 өлешендәге 4 пункт).<br>Урманнарны җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма чыганакларын эшләү буенча эшләр башкару максатларында файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми: |

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнарны файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | а) бульдозер ярдәмендә агачларны аудару һәм урман кишәрлекләрен агач үсемлекләреннән чистарту, чик буе полосаларын һәм урман авызларын агач калдыклары белән чүпләү, урман авызындагы агачларның кәүсәләрен һәм скелет тамырларын зарарлау, җәйге чорда яңа киселгән үзагачларны махсус чараларсыз гына урманда саклау;<br>б) урман утыртмаларын суга батыру һәм озак итеп су бастыру;<br>в) бирелгән урман кишәрлеге чигендәге урман үсентеләрен, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;<br>г) урманнарны төзелеш, сәнәгать, агач, көнкүреш һәм бүтән калдыклар, чүпләр белән чүпләү;<br>в) бирелгән урман кишәрлеге мәйданын һәм аның чикләрендәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>г) ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буйлап, шул исәптән урман кишәрлеше чикләрендә транспорт чараларында һәм бүтән механизмдарда йөрергә (27.12.2010 ел, № 515 Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан үзагач һәм башка урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләренең 18 пункты). |
| 13. | Сусаклагычларны һәм башка ясалма су объектларын, һәм шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү | Тыюлыклы урман кишәрлекләрендә сусаклагычлар һәм башка су объектлары, һәм шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 107 статьясының 2 өлешендәге 5 пункт). |
| 14. | Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү | Урманнарны линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) бирелгән урман кишәрлегеннән читтә урман үсентеләрен, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;<br>б) бирелгән урман кишәрлеген һәм бирелгән урман кишәрлеге чикләрендәге янәшә урнашкан территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш |

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнарны файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;<br>в) бирелгән урман кишәрлеге мәйданын һәм аның чикләрендәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>г) бирелгән урман кишәрлеге һәм тиешле сак зоналары чикләрендәге ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буйлап транспорт чараларында һәм бүтән механизмдарда йөрергә (10.06.2011 ел, № 223 Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан үзагач һәм башка урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләренең 15 пункты).<br>Урманнарны урман-парк зоналарында линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен файдалану тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 105 статьясының 3 өлешендәге 5 пункт). |
| 15. | Үзагач һәм башка урман ресурсларын эшкәртү | Сак урманнарында, һәм шулай ук махсус саклaнучы урман кишәрлекләрендә урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру тыела (Россия Федерациясе Урман кодексының 14 статьясындагы 2 өлеше).<br>Урманнарны үзагач һәм башка урман ресурсларын эшкәртү өчен файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) җир өсте һәм туфрак эчендәге су агынтыларын бозарлык, урман кишәрлекләрен су бастырырлык яисә сазландырырлык итеп эшләр башкару һәм корылмалар төзү;<br>б) бирелгән урман кишәрлеген һәм бирелгән урман кишәрлеге чикләрендәге янәшә урнашкан территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;<br>в) бирелгән урман кишәрлеге мәйданын һәм аның чикләрендәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>г) бирелгән урман кишәрлеге чикләрендәге ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буйлап транспорт чараларында һәм бүтән механизмдарда йөрергә (12.12.2011 ел, № 517 Рослесхоз боерыгы |

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнарны файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | белән расланган Урманнардан үзагач һәм башка урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләренең 6 пункты). |
| 16. | Дини эшчәнлек башкару | Дини эшчәнлек башкарганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) бирелгән урман кишәрлегеннән читтә урман үсентеләрен, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;<br>б) бирелгән урман кишәрлегеннән читтә өске сулар һәм туфрак эченә сулар агып төшүне бозарлык, урман кишәрлекләрен су бастырырлык яисә сазландырырлык итеп эшләр башкару һәм корылмалар төзү;<br>в) бирелгән урман кишәрлеген һәм аның янындагы территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;<br>в) ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буенча транспорт чараларында һәм бүтән механизмнарда үтеп керү. |